6+

# ДИН вә Мәгыйшәт

*Ий, мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! (Коръән, 3:103)*

*Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!*

№5 (250) Май– 2016 / рәҗәп – шәгъбан/ 1437

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

AZAN ИСЛАМ АВАЗЫ www.radioazan.ru

# БОЛГАР РОССИЯ ҺӘМ ХАЛЫКАРА ДӘРӘҖӘДӘГЕ ИСЛАМ ҮЗӘГЕ БУЛАЧАК

**21 майда Болгар ислам академиясенә нигез ташы салына**



**Татарстан мөфтие КАМИЛ хәзрәт СӘМИГУЛЛИН, ТР МДН рәисе:**

## «АЛТЫН – ҖИРДӘН, ГАЛИМ ИЛДӘН ЧЫГА»

2 нче бит

**Баш мөфти шәйхелислам ТӘЛГАТЬ ТАҖЕТДИН, Россия Үзәк МДН рәисе:**

## «ЯШЬЛӘРЕБЕЗ ЧЫН ИСЛАМ КЫЙММӘТЛӘРЕНДӘ ТӘРБИЯЛӘНӘЧӘК»

3 нче бит

**Мөфти шәех РАВИЛ ГАЙНЕТДИН, РФ МДН рәисе, Россия Мөфтиләр шурасы рәисе:**

## «КИЛӘЧӘК БУЫННАР КАРШЫНДА ӘМАНӘТ»

4 нче бит

# АЛТЫН – ҖИРДӘН, ГАЛИМ ИЛДӘН ЧЫГА





Гыйлем сүзе Коръәндә җитмештән артык урында кабатланып килә. Раббыбыз Коръәннең иң беренче иңгән аяте белән безгә укырга боерган: «Сине барлыкка китергән Раббың исеме белән укы!» («Галәкъ», 96:1).

Гыйлемле булу һәр мөселманга фарыз. Дөньяви һәм дини белем алу һәр заманда мөһим. Шуңа күрә дә безнең халык буыннардан-буыннарга, белем беркайчан тузмый, белем – бәхет ачкычы, дип нәсыйхәтли. Аллаһның Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дигән: «Кем гыйлем алу юлына басса, Аллаһ аңа җәннәткә алып бара торган юлны җиңеләйтә. Фәрештәләр, гыйлем алучы кешенең кылган гамәленә ризалык белдереп, канатларын җәяләр. Гыйлем иясенә күктәге һәм җирдәге җан ияләре гөнаһын гафу итүне сорыйлар, хәтта балыклар да». Менә шушы хәдистән гыйлем китергән бәхетнең ни икәне бик яхшы күренә.

Бүгенге көндә мәгълүмат кыры бик киң. Бер яктан бу күренеш бәхет ачкычын табарга, ягъни белемне тирәнәйтергә мөмкинлек бирә. Әмма интернет кирәкмәс, зарарлы, хәтта куркыныч гыйлем таралуына да сәбәпче булып тора. Соңгы ике дистә ел эчендә дөнья күләмендә эшли торган террорчы оешмаларның исламга бәйләп ялган гыйлем өйрәтүләрен күреп торабыз. Россия мөселманнарын да ялгыш юлга яртергә тырышу, бигрәк тә яшьләрнең күңеленә вәсвәсә салырга тырышу күзәтелә. Без моңа бары тик дөрес һәм файдалы, шул ук вакытта татарларның традицион рухи мирасы булып тупланган гыйлем белән генә каршы тора алабыз.

Безнең бабаларыбыз бик тә зирәк итеп: «Алтын – җирдән, галим илдән чыга», – дигән. Тарихтан күренгәнчә, бу сүзләр юктан гына әйтелмәгән. 922 елда безнең бабаларыбыз исламны рәсми рәвештә кабул иткән. Әмма татар тарихчылары һәм галимнәре әйтүенчә, ислам Болгар җирләренә Мөхәммәд Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм заманнарында ук килә. Заманында Болгарның үзенең дини мәктәбе – беренче Болгар университеты – «Белем йорты» булган. Әлеге уку йорты 1080 елда галим Якуб ибне Ногман тарафыннан ачылган. Һәм әлеге белем йорты халыкара дәрәҗәгә ия була, анда укырга дөньяның төрле төбәкләреннән җыелганнар. Тарихи документларда Болгар – дин галимнәре, фәлсәфәчеләр, фән белгечләре шәһәре буларак тасвирланган.

Бүгенге көндә ил җитәкчеләре хуплавында Болгар ислам академиясен булдыру – шушы тарихны дәвам итү ул. Татарстан Президенты Рөстәм Нургалиевич Миңнехановның, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрипович Шәймиевнең ярдәме белән академия оештырыла. Академияне гамәлгә куючылар – Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте һәм Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте.

Әлеге академиядә илебезнең мөселман өммәте элитасы – ислам фәннәре буенча галимнәр, магистрлар һәм докторлар әзерләнәчәк. Шулай ук биредә өстәмә һөнәри белем алу мөмкинлекләрен булдыру күз алдында тотыла.

Академия алдында мөһим бурычлар тора. Беренчедән, академик гыйлем татар рухи-дини мирасын саклау һәм үстерү, дини белем дәрәҗәсен күтәрү өчен кирәк. Икенчедән, бу уку йорты төрле ялган гыйлемнәргә – радикаль карашларга һәм идеологияләргә каршы тору чарасы буларак күзаллана.

Шулай ук мөселман өммәтен традицион ислам кыйммәтләренә һәм хәнәфи-мәтуриди дини мәктәбе өйрәтүләренә таянып берләштерергә ярдәм итәр, Аллаһы боерса. Болгар академиясе Россия мөселман галимнәре берлеген, Мөселман дин әһелләре өчен фәнни-белем бирү үзәген, Болгар ислам китапханәсен, Татар дини мирасын өйрәнү үзәген үз эченә алачак.

Без чын мәгънәсендә зур тарихи көннәрдә яшибез. 29 апрельдә Казанда Болгар ислам академиясе республика җитәкчелеге катнашында җәмәгать-челеккә тәкъдим ителде. Аллаһ боерса, 21 майда – Болгар җыены көнне Болгарда ислам академиясе нигезендә бөтенебез бергәләп догалар кылырбыз, олы эшне башлап тәкъбирләр әйтербез.

Аллаһы Тәгалә җитәкчеләребезнең дә, дин әһелләренең дә, һәм гомумән, Болгар ислам академиясен булдыру юлында үз өлешен керткән һәрбер кешенең башкарган эшләрен уң кылып, илебездән яңа буын татар дин галимнәрен чыгарырга насыйп итсә иде. Амин.



Татарстан мөфтие
**Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# ИСЛАМ ДИНЕН РӘСМИ ТӨСТӘ КАБУЛ ИТҮ КӨНЕ БЕЛӘН!

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**
**Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәракәтүһү!**

21 май – республикабызда Идел буе Болгар дәүләтенең 922 елда ислам динен рәсми төстә кабул иткән көне буларак билгеләп үтелә. Шунысы да мәгълүм, Аллаһы Тәгалә ихтыяры белән бабаларыбыз ислам юлын бу вакыттан күпкә иртәрәк чорда сайлаган. Бүгенге көннәргә кадәр сакланып килгән тарихи чыганаклар шул хакта сөйли. Бүген без, Аллаһка шөкер, бабаларыбыз сайлаган ислам юлын дәвам итүчеләрдән. Исламның күркәмлеген бабаларыбыз кебек үк аңларга, рухи мирасыбыз хикмәтенә төшенергә һәм аны үзебездән соң килгән буынга җиткерергә тырышабыз.

Ислам динен рәсми кабул итү көне – мөселманнарның Россиядә җирле халык булуына да бер дәлил. Күп гасырлар дәвамында илебездә мөселманнар өммәте динебезгә таянып эш йөрткән, тормышларын алып барган. Дин – бар буын кешеләре өчен дә Аллаһы Тәгаләнең нәсыйхәте, нигъмәте. Күп гасырлар дәвамында ислам татар халкының алга алып баручы рухи көче, иманы булган һәм җәмгыятьнең әдәп-әхлак нигезен тоткан. Алга таба да шулай булырга язсын.

Барчабызга да Раббыбызның иксез-чиксез рәхмәтләренә ирешергә, гомерләребезне



хәерле итеп үткәрергә насыйп итсен! Ил-көннәребезгә тынычлык-иминлек, бәрәкәт бирсен иде!

Татарстан мөселманнары
Диния нәзарәте рәисе, мөфти
**Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# ЯШЬЛӘРЕБЕЗ ЧЫН ИСЛАМ КЫЙММӘТЛӘРЕНДӘ ТӘРБИЯЛӘНӘЧӘК

**29 апрельдә Казанда тарихи-мәдәни һәйкәлләрне торгызу белән шөгыльләнүче «Яңарыш» республика фонды попечительләр советының киңәйтелгән утырышында Болгар ислам академиясе проекты җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде. Анда катнашкан Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе, баш мөфти, шәйхелислам Тәлгать Таҗетдин үзенең уй-фикерләре белән уртаклашты.**



– Әлхәмдүлилләһ! Бу – тарихи вакыйга. Безнең әллә ничә буын бабаларыбыз хыялланган зур проект тормышка ашу алдында тора. Борынгы бабаларыбыз, белемне ислам диненең таянычы итеп, һәрвакыт яңалыкка, мәгърифәткә омтылган. Мәгърифәт белән сугарылган ислам традицияләре галимнәребезнең каһарманлыгы аркасында гасырлар буе уңышлы дәвам иттерелде, буыннардан-буыннарга тапшырылып килде. Алар арасында Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Исмәгыйль Гаспринский, Ризаэддин Фәхреддин, Садри Максуди, Йосыф Акчура, Һади Атласи, Гаяз Исхакый, Әхмәтзәки Сафиуллин һәм башка мәшһүр татар мәгърифәтчеләре һәм дин әһелләре күренекле урын алып тора. Без бөтен дөньяга билгеле булган галимнәребез – ислам дине тәгълиматчылары белән хаклы рәвештә горурланабыз. Бүгенге көндә үзебезнең борынгы ислам дине мәктәбен, хәнәфи мәзһәбе тәгълиматы һәм фикъһы үзәген яңабаштан торгызырга башлангыч мәйданчыгыбыз бар. Ул мәктәп, бөтен ислам дөньясында абруй казанып, тарихи чорлар дәвамында ислам тәгълиматы үсешенә зур өлеш керткән.

Бу уңайдан дини мәгариф системасын торгызуда ярдәм иткәне өчен без дәүләтебезгә, шәхсән РФ Президенты Владимир Владимирович Путинга бик рәхмәтле. Мөселман яшьләренең хәзер чын мөселман кыйммәтләрендә, үзебезнең традицион ислам тәгълиматы үрнәгендә тәрбияләнергә, белем алырга мөмкинлекләре булачак, без моңа бик шатбыз.

**– Болгар ислам академиясе бинасына Сез үз проектыгызны тәкъдим иткән идегез. Хупланган проектта тәкъдимнәрегез ни дәрәҗәдә чагылыш тапкан?**

– Әлбәттә, бу грандиоз проектны һәркайсыбыз үзе күрергә теләгәнчә тормышка ашырырга, үз өлешен кертергә тырышыр иде, әмма бүген булган мөмкинлекләрдән чыгып эш итәргә кирәк. Һәм, минемчә, без максатка ярашлы юлдан барабыз. Иншаллаһ, вакыт кирәкле төзәтмәләрне кертер. Хәзер безнең төп бурычыбыз – бу эшне системалы төстә алга таба алып бару, мөселман дин әһелләрен әзерләү өчен үз илебезнең ислам тәгълиматы мәктәбе кануннарына туры килгән универсаль мәгариф программасы әзерләү, дип уйлыйм. Мин ышанам, моның өчен бездә бөтен алшартлар да бар.

**– Болгар ислам академиясе төзү башлангычы белән Россиянең иң эре үзәкләшкән мөселман дини оешмалары – Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте һәм Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте чыкты. Ә ни өчен нәкъ менә Болгар сайлап алынды?**

– Болгар – безнең барыбыз өчен дә мөкатдәс урын, борынгы бабаларыбызның рухи мәдәният үзәге. Нәкъ менә биредә алар беренче тапкыр исламны кабул иткәннәр, бу җирдән безнең үзенчәлекле цивилизация башлана. Бу – рухи көч ала торган, милли үзаңыбыз уяна торган урын. Моннан да кулайрак җирне табу мөмкин түгел, дип уйлыйм.

**– Кадрлар мәсьәләсен хәл итүнең нинди юлларын күрәсез?**

– Элекке дини белем бирү системасын торгызу бүген бөтен Россия мөселман җәмәгате өчен бик зур әһәмияткә ия. Россиядә беренче дини уку йортларыннан булган, Үзәк Диния нәзарәте каршында Уфада ачылган Россия ислам университеты бу өлкәдә үзеннән зур өлеш кертте. Анда 1,5 мең ислам дин әһеле укып чыкты. Бу мөһим эштә Россиянең башка ислам университетлары да катнашты. Моннан тыш Болгар ислам академиясендә укыту процессын барлап тору өчен мөселман галимнәре арасында билгеле булган шәех, Амман халыкара университеты профессоры, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең 42 нче буын оныгы Абдурразак әс-Сәгъди чакырылды. Бу вуз өчен һичшиксез зур табыш!

**– Болгар ислам академиясенең конкурентлыкка сәләтлелегенә ничек ирешергә? Сез аның эшчәнлеген ничегрәк күз алдына китерәсез?**

– Соңгы елларда Россиядә мөселман белем бирү учреждениеләренең саны шактый артты. Бердәм укыту стандартлары системасын төзеп, академия, төп ислам вузы буларак, бу мөһим өлкәнең алга таба алып баручы локомотивы булырга тиеш, дип саныйм. Киләчәктә, Аллаһы боерса, безнең рухи-мәгърифәт үзәге Россия, БДБ илләре өчен генә түгел, ә бәлки бөтен дөньяга мөселман галимнәре әзерләү урыны булачак.

# КИЛӘЧӘК БУЫННАР КАРШЫНДА ӘМАНӘТ



**Мөхтәрәм дин кардәшләрем!**

Динебез исламның күркәм сәламе – әссәләмү галәйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһү диеп, барчагызны Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте, Россия Мөфтиләр шурасы һәм шәхсән үз исемемнән ихлас күңелемнән сәламлим!

Милләтне рух яшәтә, рухны – мәгърифәт. Өммәтнең һәм милләтнең киләчәген кайгыртып, без гыйлем һәм мәгърифәт учагы – Болгар ислам академиясен булдыру эшенә керештек. Сүземнең башында иң элек һәрбарча олуглауларга лаек Раббыбыз, галәмнәр Хуҗасы Аллаһы Сөбханә вә Тәгаләгә, Болгардагы гыйльми башлангычны хәерле кыл, Болгар ислам академиясенең киләчәген киң һәм шөһрәтле кыл, дия-дия дога кылам.

Аллаһы Раббыбыз Коръәни Кәримендә пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә шундый доганы әйтергә боера: «Йа Рабби, гыйлемемне арттыр». Акыл эшчәнлеген күз белән күреп булмый, зиһен – матди нәрсә түгел, ләкин зиһенсез, фикерсез бу дөньяда бер генә максатка да ирешеп булмый һәм ахирәткә дә әзерләнү мөмкин түгел. XXI гасыр башында Татарстан Республикасы, гомум татар милләте Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов, беренче Президент, ә хәзерге көндә Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев кебек шушы хакыйкатьне төшенүче әйдаманнары булуы белән бәхетле.

Сәяси җитәкчеләрнең киләчәккә карап фикер йөртүләре, дин һәм милләт пәрвәрләре булуы аркасында Татарстан башкаласында Кол Шәриф мәчете торгызылды, мәчет-мәдрәсәләрдә, мәхәлләләрдә тормыш киң сулыш алды, Изге Болгар җирлеге борынгыдан килгән дан-шөһрәтен кайтара башлады. Шушы хәрәкәтнең тагын бер баскычы – Болгар ислам академиясен булдыру, ягъни гыйльми яктан тагын бер дәрәҗә өскә күтәрелү, офыкларны киңәйтү. Бу адымны бөек Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләре, Муса Җарулла, Ризаэддин Фәхреддин хәзрәтләренең кылган догалары, киләчәк буыннарга теләкләренең кабул булуы дип аңларга кирәктер. Иншаллаһ, шулай булсын.

Мөфти Ризаэддин хәзрәт Фәхреддин өммәтебезнең «мәдәни милләт» булып яшәвен, алга китүен теләгән, шуның турыда яза. Мәдәнилек исә – бер урында тапталып тормау, фикер хәрәкәте, аңлы-белемле яшәеш. Шул оеткы булганда милләтнең матди һәм мәдәни торышы да күркәм төстә үсеш ала. Һәр милләт үзе арасындагы гыйлем ияләренә, остазларга хөрмәт-илтифат күрсәтергә бурычлы, голәма өчен иҗат итү шартлары тудырырга тиеш.

Боларны аңлап, илнең бөтенлеген, бердәм дәүләт эчендә һәр милләтнең һәм диннең ирекле үсүен күздә тотып, Болгар ислам академиясен гамәлгә ашыруга Илбашы Владимир Владимирович Путин да теләктәшлеген, хуплавын белдерде. Болгар ислам академиясен төзү турында иң беренче булып ул үзе Мәскәү җамигъ мәчетен ачу тантанасында мөселман дөньясыннан һәм Россиянең төбәкләреннән килгән меңәрләгән кунаклар алдында әйтте.

Болгар ислам академиясе бинасына нигез ташы салу тантанасына да бик күп илләрнең югары дәрәҗәле вәкилләре, күпсанлы имамнар, зыялылар җыела. Бу – безнең бөтен дөнья каршында, киләчәк буыннар алдында үз өстебезгә алган әманәтебез. Президент Владимир Путинның, милләттәшләребез, дин кардәшләребезнең ышанычын аклау өчен без бөтен тырышлыгыбызны куярга бурычлы.

Болгар ислам академиясе дөньякүләм танылган университетлар дәрәҗәсендә исламият белгечләре, фикерләрен теләсә кайсы җәмәгатьтә туган телендә, шуның өстенә гарәп, инглиз һәм башка телләрдә ирекле яклап чыга алырлык галимнәр, киң катлам мөселман интеллектуалларын әзерләргә тиеш. Бирелгәге фәнни кафедралар ислам энциклопедияләре чыгару, дәреслек-программалар язу, китаплар нәшер итү кебек катлаулы фәнни максатлар куеп, шуларны башкарып чыгу өчен җаваплы булыр дип өметләнәбез. Нәтиҗә буларак, бу Болгар ислам академиясе милләтнең, өммәтнең әйдәп баручы рухи һәм интеллектуаль көченә әверелеп, дөнья милләтләре арасында безгә кабатланмас үз урыныбызны табып, киләчәккә ышаныч күзе белән карауны, рухи кыйммәтләребезнең буыннан-буынга түгелми-чәчелми күчеп килүен тәэмин итәр.

Куелган максатка ирешергә без сәләтлеме бүгенге көндә? Мөхтәрәм Минтимер ага Шәймиев сүзләре белән әйткәндә, безнең халык аңлы да, белемле дә, булдыра да. Соңгы еллар дәвамында уңышлы башкарып чыккан Изге Болгарны торгызу, аны ЮНЕСКО дөньякүләм мәдәни һәйкәлләр исемлегенә кертү, Ак мәчет комплексын төзетеп сафка бастыру мисаллары ышанычыбызны арттыра. Бу өметне бердәмлегебез, тырышлыгыбыз белән ныгыту зарур.

Аллаһка шөкер, берничә айга сузылган әзерлек нәтиҗәсендә Болгар ислам академиясе рәсми теркәлү узды, юридик яктан гамәлгә керде. Булачак бинаның проектлары да әзер һәм расланган. Тәүге адымнарны Раббыбыз рәхмәте белән уңышлы башладык. Алга таба да матур эшләү өчен мин түбәндәге шартларны үтәү кирәк дип саныйм:

бердәм булу, үзара ихтирам белән эш итү;

төрле дәрәҗәдәге хакимият белән хезмәттәшлек, аңлашып, килешеп эшләү;

халык белән эшләү, Болгар ислам академиясенең әһәмиятен аңлату;

руханилар һәм дөньяви гыйлем учакларында иҗат итүче галимнәрнең хезмәттәшлеге;

үзебезнең милләтне XIX-XX гасырларда таныткан голәма иҗатларына, ислах мәдәрис ягъни белем бирүне яңарту турындагы фикерләренә таяну;

чит илләрдә эшләүче дин кардәшләребез белән ныклы фәнни күперләр булдыру, тәҗрибә туплау;

яшь буын дин белгечләрен, имамнарны гыйльми эшчәнлеккә җәлеп итү, галимнәр сафларын яшьләр хисабына арттыру.

Милади ел исәбе белән 922 елда Багдад хәлифәсе әл-Мөктәдир илчелеге Идел буе Болгар дәүләтенә килгәч, Әхмәд ибне Фадлан язып калдырганча, илчеләр биредә гөрләп эшләүче мәчет-мәдрәсәләр, ислам дине нигезендә үсүче шәһәр мәдәниятен күрә һәм шакката. 2022 елда, ата-бабаларыбызның исламны рәсми дин итеп кабул итүләренә 1100 ел тулганда без Изге Болгар җирендә ныклап эшләп киткән, иң төпле галимнәрне, иң сәләтле шәкертләрне үзенә тартып китергән Болгар ислам академиясен күрик, диеп догалар кылам. Амин.

**Мөфти шәех Равил Гайнетдин,**
Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,
Россия Мөфтиләр шурасы рәисе

# БОЛГАР ИСЛАМ АКАДЕМИЯСЕ ТӨЗЕЛҮ – ДӘВЕР ВАКЫЙГАСЫ



– Болгар ислам академиясен төзүне мин дәверебезнең төп вакыйгасы дип саныйм. Бу бик мөһим карар һәм ул дәүләтебез башлыгы Владимир Владимирович Путин тарафыннан да хупланды, бу хакта күп тапкырлар халык алдында да әйтте. РФ Фән һәм мәгариф министрлыгы лицензиясен алганнан соң, академия бинасын көнчыгыш стилендә төзү эшләре башланды. Проектны, белүемчә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» республика фонды җитәкчесе Минтимер Шәймиев раслады; Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, мөфти урынбасары, Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин һәм башкалар аны хупладылар. Миңа калса, проект бик уңышлы, уйланылган һәм эксплуатация өчен бик уңайлы.

**– Мәскәүдә, Казанда ислам югары**



**уку йортлары бар. Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, бездә ислам дине галимнәре юк, шуңа күрә дөньяда барган җитди әйберләрне аңлатып бирә алмыйбыз, дигән иде. Болгар ислам академиясе алдында торган бурычларның берсе шулмы?**

– Мин сорауны болай кую белән килешеп бетмим. Әйе, бездә вузлар бар, тирән гыйлемле кешеләр дә бар, әмма аларны берләштерерлек мәйданчык юк – проблема менә нәрсәдә. Форсаттан файдаланып, мин Болгар ислам академиясен гамәлгә куючыларның игътибарын Бохарадагы «Мир-Араб» мәдрәсәсенең уңай тәҗрибәсенә юнәлтәсем килә. Күп еллар укыту дәвамында аннан бер генә экстремист та чыкмады! Һәм алар гыйлем биреп кенә калмыйча, Евразия пространствосы өчен традицион булган ислам дине тәгълиматы мәктәбен саклап кала алдылар.

Үзегез дә безнең хәзерге дин әһелләренең вәгазьләү стильләрен күзәтә торгансыздыр, мөгаен: кемнәрдер мәхәллә халкына чит ил дин әһелләре кебек тавышын күтәреп тәэсир итмәкче була. Татарлар моны кабул итми, безнең менталитет башка: сиңа кычкыра башласалар, әйткәнне аңлап та, кабул итеп тә булмый. Әйдәгез, безнең өлкән имамнарыбызны искә төшерик әле, алар вәгазь сөйләү сәнгатен ничек яхшы беләләр иде – шул дәрәҗәдә хөрмәт белән, аңлаешлы итеп, кирәк урында чама белән генә катырак та итеп сөйлиләр иде. Урта Азиядә бүген дә, мәсәлән, Үзбәкстан имамнарының вәгазьләрен тыңлаганда эрепләр китәсең – алар динебезне сүз белән ничек матур итеп тапшыра беләләр.

Хәзер бездә артистлар күбәйде – татарлар арасында 3 меңгә якын диләр, барысы да җырлый, әмма бик азлары гына җырның мәгънәсен, моңын, матурлыгын, хис-кичерешләрне тыңлаучы күңеленә ирештерә ала. Мин күп җырчыларны тыңлыйм, әмма, мәсәлән, Әлфия Авзалова кебек җыр сүзенең мәгънәсенең көчен җиткерә белүче артистлар бик аз. Бу аның табигатеннән килә дип уйлыйм. Бәлки, хәзер әйтәсе сүзләрем бераз сәеррәк тә тоелыр, академиядә сөйләм сәнгатен, сөйләм кагыйдәләрен, риториканы өйрәтергә кирәк дип уйлыйм. Хәзерге заманның күп кенә дин әһелләре Урта Азиядә укып кайтты, бердәм дини белем бирү мәйданы иде, бер үк китапларны укыдык. Кызганычка, башка җирләрдә бу нәрсәләр (вәгазь сөйләү сәнгате) югалган, ә Урта Азиядә сакланганнар. Минем уйлавымча, Болгар ислам академиясенең Голәмалар шурасына моңа игътибар итәргә һәм бу уңай тәҗрибәне мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга кирәк.

**– Болгар ислам академиясенең ректоры кем булырга тиеш – россиялеме, әллә чит ил кешесеме? Сез бу вазыйфада кемне күрәсез?**

– Россия бик зур ил, анда 20 миллионнан артык мөселман яши, шушы зур илебездә лаеклы кеше табылыр дип уйлыйм. Янәшәсендә чит ил кешесе булса да ярый. Тирән гыйлеме булган яшь галимнәребез дә бар. Болгар ислам академиясенең ректоры Россия гражданины булырга тиеш дип саныйм.

**– Болгар ислам академиясе лаеклы укытучыларны туплый алыр микән?**

– Соравыгыз өчен рәхмәт, сез хәзер бик мөһим мәсьәләне кузгаттыгыз. Беренчедән, дөньяда Россия белән хезмәттәшлек итәргә кызыксыну зур. Дөньяның мәшһүр ислам дин гыйлеме үзәге булган Иракны бомбага тоттылар, бәһасез китапларны, китапханәне яндырдылар, күп галимнәр аннан качып китте. Сүриядә сугыш бара, ә Дәмәшкъта галимнәр күп иде. Узган ел Сүриядә шәех Рамазан әл-Бутыйга багышланган конференциягә баргач, анда атаклы галимнәр белән очраштык. Галимнәр династиясе, барысы да танылган ислам дине галимнәре. Алар да Россия белән хезмәттәшлек итәргә, бездә эшләргә риза булган укытучыларны җибәрергә әзер. Күптән түгел Рәфыйк Мөхәммәтшин җитәкчелегендәге Ислам мәгарифе советы делегациясе Мисырда булып кайтты. Әл-Әзһәр университеты җитәкчелеге белән сөйләшкәннән соң, алар Әл-Әзһәргә Россия мөселманнарын Ислам мәгарифе советы тәкъдимнамәсе нигезендә генә кабул итү турында килештеләр. Бу дәресләргә йөрмичә, бишәр ел бер курста утырып торучы шәкертләр булмасын өчен шулай эшләнде. Әл-Әзһәр шәехләре Мисырдан Болгарга үз галимнәрен җибәрергә теләк белдерделәр. Башка илләрнең, мәсәлән, Марокконың ислам галимнәре дә Болгар ислам академиясе белән хезмәттәшлек итәргә әзер. Укытучыларны тупларга була, чөнки үзләре үк кызыксынып торалар, килерләр.

Татарда шундый бер мәкаль бар: «Өрә белмәгән эт өенә бүре китерә». Шикле репутацияле галимнәрне җәлеп итмәскә кирәк. Без кемне чакыруыбызны белергә тиешбез. Бу эшкә алыначак кеше үз кандидаты өчен тулысынча җаваплы булсын. Моны килештереп эшләргә кирәк. Мин Урта Азия уку йортлары белән сөйләшергә тәкъдим итәр идем, безнең эшчәнлектә аларның тәҗрибәсен дә исәпкә алырга кирәк.

**– Бездә бәхәсле сораулар буенча фәтва чыгара алырдай галимнәр бармы?**

– Россиядә андый галимнәр бар. Әмма, әйткәнемчә, барлык юнәлештә эшләүче галимнәр һәм дин әһелләре, бер өстәл артына утырып сөйләшеп, киңәшләшеп фәтва чыгарыр өчен безнең уртак мәйданыбыз юк иде. Коръәнебез бер, динебез – бер, фәтваларыбыз да мәгънәви яктан аерыла алмый.

Бүгенге ислам галимнәре заманча, тирән гыйлемле, позитив фикерләүче булырга тиеш. Һәм килеп чыккан теге яки бу проблема буенча уртак карарлар кабул итәргә кирәк. Мәсәлән, хиҗап мәсьәләсе шундый авыр мәсьәлә иде, без аны хәл итә алдык. Мин үзем Идел буе төбәкләренә берничә тапкыр бардым. Мәктәп әйтә: «Хәзрәт, карагыз инде боларның кыяфәтенә, Ирандагы кебек бит», – ди. Мин түрәләр белән дә, мөслимәләр белән дә сөйләштем, һәр ике як та үпкәләгән иде. Беләсезме, проблема нидә? Аларга, мәгариф департаменты озын итәктән, биек якалы блузкадан, ак яулыктан йөрергә рөхсәт итә, дип әйтеп торалар. Ә кызлар, алай булмый, чөнки безгә бер шәех телефоннан яулыкны күзгә хәтле төшереп бәйләргә кирәк дип әйтте, диләр. Мин шуңа аптырадым: ул төбәктә әллә ничә мөфти бар, әмма мөслимәләр аның фикерен тыңламыйча, телефон аша чит ил шәехенең фәтвасын алалар. Аның нинди шәех булуы, кайдан шалтыратуы да билгесез бит әле... Шунда фәтва чыгару үзәге булса, фәтва чыгарыр идек тә, яулык ябуның тәртибен аңлатып бирер идек...

(Мәскәү һәм Чувашстан мөфтие
**Әлбир Кргановның**
business-gazeta.ru газетасына
биргән интервьюсыннан)

# Рәфыйк Мөхәммәтшин: «Болгар ислам академиясе мөселман мәгарифе системасын яңа баскычка күтәрәчәк»

**Республика мәдрәсәләрендә һәм югары уку йортларында бердәм мәгариф стандартларын кертү, Ислам мәгарифе советын оештыру, Мисырның Әл-Әзһәр университеты җитәкчелеге белән килешү төзү, Болгар ислам академиясен ачуга әзерлек – Татарстан мөфтие урынбасары, Россия ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшинның «Азан» радиосы алып баручысы Илмир Хәбибуллинга биргән интервьюсында бу һәм башка бик күп темалар күтәрелде.**




**– Рәфыйк әфәнде, Сез Ислам мәгарифе советын җитәклисез. Бу совет нәрсә белән шөгыльләнә, шул хакта сөйләгез әле.**

– Мәгълүм булганча, бүгенге көндә Россиядә 80 нән артык мөселман уку йорты эшләп килә. Алар статуслары буенча да, белем бирү дәрәҗәсе буенча да төрле. Башта Россия мәгариф системасының нинди хәлдә булуын ачыкларга, ихтыяҗлары булганнарына методик яктан ярдәм итәргә кирәк иде. Ислам мәгарифе советы, шуларны хәл итүне күздә тотып, алты ел элек оешты. Дөрес, анда 35 мөселман уку йорты гына керә, шулай булса да без хәзер бердәм мәгариф мәйданында эшлибез. Узган ел урта-һөнәри уку йортлары өчен бердәм мәгариф стандартлары әзерли башладык. Татарстан мәдрәсәләренә бу стандартлар кертелде инде, югары уку йортлары өчен мәгариф стандартларын әзерләүне төгәлләп утырабыз. Димәк, тиздән Ислам мәгарифе советы ике стандарт – мәдрәсәләр һәм югары уку йортлары өчен мәгариф стандартлары нигезендә эшли башлаячак. Бу инде яңа таләпләр дигән сүз. Кайсы уку йортлары шушы таләпләрне тормышка ашыра, аларга Ислам мәгарифе советы финанс ягыннан да, фәнни-методик планда да ярдәм итәчәк.

Совет эшчәнлеге бөтен Россияне колачлый, Төньяк Кавказдан Дагыстан, Чечня, Кабарда-Балкария, Ингушетия дә керә. Кавказ уку йортлары, гадәттә, бик көчле. Ислам мәгарифе советы ел саен мөселман уку йортлары студентлары өчен Бөтенроссия олимпиадасы уздырып килә. Һәм анда, кагыйдә буларак, Төньяк Кавказ мөселман уку йортлары студентлары җиңеп чыга. Бу Кавказда дини мәгариф системасының үз традицияләре югалмаганлыгы турында сөйли. Аларда тәрикать тә сакланган, билгеле шәехләре дә бар. Хәтта Совет власте елларында да тауларда мәдрәсәләре эшләп торган. Ә Үзәк Россия турында сөйләгәндә, кызганыч, безнең традицияләр югалып бетә язган. Шуңа күрә мөселман мәгарифе системасын торгызу авыррак, барысын да өр-яңадан башларга туры килә.

**– Ә Әл-Әзһәргә укырга керергә теләүчеләрне Ислам мәгарифе советы аша сайлап алу ничек башкарылачак?**

– Аның механизмы эшләнмәгән әле. Ике арада килешүгә ирешелде, шәех Әхмәт Таип, хәзердән башлап Россия студентлары Әл-Әзһәргә бары тик Ислам мәгарифе советы тәкъдимнамәсе буенча гына укырга кабул ителәчәк, дип ышандырды. Сайлап алуга килгәндә, бездә үзәкләшкән дини оешмалар булганлыктан, Совет бөтен җаваплылыкны үз өстенә генә алмас, мөгаен. Без инде, һичшиксез, белем дәрәҗәсен карарбыз. Әмма Әл-Әзһәрне тәмамлагач, бу мөселман кая барачак – алдан ук шул хакта да уйларга тиешбез. Әллә ул Сүриягә, ИГИЛга юл тотар, Аллаһ сакласын! Бу яктан караганда, әлбәттә, Диния нәзарәтләренә дә зур җаваплылык йөкләнә, чөнки алар үз төбәкләреннән Әл-Әзһәргә укырга китәчәк яшь кеше белән таныш, аның идеологик карашларын, нинди мәзһәбтә булуын беләләр. Шулай итеп, уртак тырышлык белән ул исемлекне төзербез дип уйлыйм.

**– Әл-Әзһәргә укырга керүчеләргә гарәп телен белүдән тыш тагын нинди таләпләр куела?**

– Әл-Әзһәр Россия югары мөселман уку йортлары дипломнарын таный, ягъни безнең бакалавриатны тәмамлаучылар Әл-Әзһәр бакалавриатының 1 нче курсына керәчәк. Әлбәттә, без магистратурага керүләрен теләр идек. Безнең бакалавриат тәмамлаучылар Индонезиядә, Малайзия, Марокко, Төркия уку йортларында магистратурада уңышлы гына укыйлар. Әмма Әл-Әзһәр – бүтән, Әл-Әзһәр – дәүләт эчендәге дәүләт кебек ул. Әл-Әзһәрнең мәктәптән алып докторлык диссертациясенә кадәр үз белем бирү системасы төзелгән. Ул система VIII гасырдан бирле килә, хәзерге этапта шул системага эләгү дә безнең өчен бик яхшы. Иншаллаһ, тора-бара бакалаврларыбыз үзләренең яхшы әзерлекләрен күрсәтерләр, шул чагында магистратура турында да сүз кузгатырга мөмкин булыр.

**– Хәзерге вакытта чит илдә укып кайткан яшь кешеләргә Россиягә кайтып эшкә урнашканда берәр төрле таләп куеламы?**

– 90 нчы елларда бездән чит илләргә укырга бик күп кеше китте. Кызганычка, аларның кайберләре идеологияләре шикле булган төрле халыкара оешмаларга барып эләкте. Аннан соң бу егетләр Россиягә кайтып, биредә проблемалар тудыра башлады. Моның төп сәбәбе шул – алар чит илгә мәктәпне тәмамлауга ук киттеләр, бернинди дини белемнәре юк иде, хәтта намазга да чит илдә генә бастылар, үзаңнары шунда – чит җирләрдә формалашты. Һәм, табигый ки, яхшы нияттән чыгып, мөселманнарның Диния нәзарәте, мөселман лидерлары бирегә төрле финанс фондларын җәлеп итте. Күп булды алар... 90 нчы еллар безгә диннәр буенча ил сәясәтенең бик төгәл булырга тиешлеген күрсәтте. Әлбәттә, бездә дин дәүләттән аерылган, әмма шуны яхшы аңларга тиешбез – мөселман өммәтендә килеп чыккан проблемалар соңыннан бөтен җәмгыять проблемасына әвереләчәк. Бүгенге көндә дәүләт шушыны анализлау белән мәшгуль. Ислам мәгарифе советы да Әл-Әзһәрне, башка чит ил уку йортын тәмамлап туган җиребезгә аек акыллы, адекват кешеләр кайтсын, монда проблемалар тудырмасын өчен бу процессны контрольдә тотарга тырыша.

Бүгенге көндә Россиядә дәүләт белән үзәкләшкән дини оешмаларның мәгариф системалары арасында мөнәсәбәтләр урнаштыру процессы бара. Дәүләт тә мөселман яшьләрен укыту яклы, без моны Әл-Әзһәр мисалында да күрәбез. Россия Президенты ачык итеп әйтте: «Бүгенге көндә үзәкләшкән дини

оешмаларның төп бурычларының берсе – үзебезнең дини тәгълиматчылар мәктәбен торгызу». Моның өчен без яшьләрне укытырга тиеш. Россиядә әлегә андый мөмкинлекләр юк, ә чит илдә укытыр өчен үзебездә гыйлеме ягыннан да, дини карашлары буенча да нык булган бакалаврлар әзерләргә кирәк. Чит илгә укырга чыгып киткән яшь кеше анда алган белемне тәнкыйди күзлектән карап бәяли дә белергә тиеш.

**– Чит илдә белем алып кайткач, дини эшчәнлеккә керешер алдыннан ул яшь белгеч нинди дә булса махсус комиссия тикшерүе узамы?**

– ТР МДНнең аттестация комиссиясе бар. Көч структураларында, Диния нәзарәтендә сорау тудырган кайбер имамнарны шушы комиссиягә чакырталар, алар гакыйдә, фикъһ буенча һәм башка сорауларга җавап бирәләр – бу гадәти хәл буларак кабул ителергә тиеш. Моны кысрыклау дип карарга кирәкми. Сүз бит белем турында гына бармый, дини белем идеологик күзаллаулар белән тыгыз бәйләнгән. Шунлыктан, әлбәттә, без кем кайтты икән дип кызыксынырга тиеш, хәтта ул Әл-Әзһәрне тәмамлап кайтса да.

Россия ислам институтында Әл-Әзһәрне тәмамлаган дистәгә якын кеше эшли. Әйе, алар хәнәфи мәзһәбендә, мәтуриди гакыйдәсен таныйлар, әмма без Россия ислам мәгарифе системасы, татар ислам дине тәгълиматчылары традицияләре турында сүз алып барабыз икән, алар аны белми, чөнки өйрәнмәгәннәр. Әгәр Шиһабетдин Мәрҗанине, Курсавины, аларның фикъһ, гакыйдә, тәфсир буенча мәшһүр хезмәтләрен белмисең икән, син инде Россия югары уку йортының, мәдрәсәсенең дәрәҗәле укытучысы була алмыйсың.

Бездә, мәсәлән, иң мәшһүр тәфсирләр булып Ногмани яки Хәмиди тәфсирләре санала. Читтә укып кайтканнар аны да белми. Күз алдына китерик, чит илдә абруйлы дини уку йортында бик яхшы белем алып кайткан яшь егет бер татар авылына барып төшә ди, ә анда мәчеттә, Ногмани тәфсирен тотып, бер бабай утыра. Аралаша торгач, безнең гыйлемле яшь мулланың бу тәфсирне хәтта күргәне дә юклыгы ачыклана. Мәхәллә кешеләренең әлеге отличникка мөнәсәбәте ничек була инде шуннан соң! Менә бу яктан караганда чит илләрдәге мөселман вузларын тәмамлаучыларның безнең җирлеккә яраклашу проблемасы бар шул әле.

Бүген мөселман уку йортларында, мәчетләрдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте уставы буенча бары тик хәнәфи мәзһәбендәге имамнар гына эшләргә тиеш. Әмма бу башкаларын кыерсыталар, кысрыклыйлар дигән сүз түгел. Мәхәллә кешесе, гаргади мөселман буларак бу мәчеткә килеп гыйбадәт кылудан аны беркем дә тыймый, әмма имам хәнәфи мәзһәбендә, мәтуриди гакыйдәсендә булырга тиеш. Чөнки бу бит оешма, ул кабул ителгән устав нигезендә имамнарга үзенең таләпләрен дә куя.

**– Әл-Әзһәр белән төзелгән килешү кайчан гамәлгә керәчәк?**

– Сентябрь аеннан башлап алар Ислам мәгарифе советы тәкъдимнамәсеннән башка бер кешене дә укырга кабул итмәячәкләр. Безнең бакалавриат белемен тануга килгәндә, бусы инде үзебездән дә тора. Ягъни без аларның таләпләренә җавап бирерлек программа төзеп җибәрергә тиеш. Әйткәнемчә, югары уку йортлары стандартлары буенча эшне төгәлләп килəбез. Стандартлар эшләү бик җиңел эш түгел. Компетенция төшенчәсе бар бит әле, матур сүз өчен генә әйтү түгел. Без: «Ә кемнәрне әзерлибез соң?» – дигән сорауны бирергә тиеш. Имам-хатыйблар әзерлибез икән, ул имам-хатыйбка нинди белемнәр бирергә кирәк? Гарәп телен тирәнтен өйрәтергәме? Үзенең камил гарәп теле белән авыл мәчетендә нишләр икән инде ул? Аның гакыйдәсе көчле булырга тиеш. Аннары бүген ислам хокукы – фикъһ буенча бик күп сораулар туа. Бу – җеназа, никах, талак, аерылышканда мал бүлү мәсьәләләре. Кадрларны без менә шушы компетенция кысаларында әзерләргә тиеш.

**– Мәдрәсәләргә бердәм мәгариф стандартларын керткәндә нинди кыенлыклар белән очрашырга туры килде?**

– Бу мәсьәләне без Татарстанда беренчеләрдән булып күтәрдек. Мәдрәсә ректорлары хуплап каршы алдылар, дип әйтә алмыйм. Хәтта бик нык каршы тордылар. Аларны да аңларга була, чөнки финанс мөмкинлекләре аз, укытучыларга кытлык бар. Ә стандарт 24 фәннән белем бирү дигән сүз. Безнең мәдрәсәләрдә моңа кадәр 10 лап фәннән укыталар иде – Коръән, гарәп теле, хәдис, гакыйдә, фикъһ... Әмма гомуми дини белем бирергә уйлыйбыз икән – бу гына аз. Без һәрбер мәдрәсә җитәкчелеге белән сөйләшеп чыктык, һәр мәсьәләне алар белән килештердек һәм уртак бер фикергә килдек. Бик зур эш башкарылды. Безгә кадәр Россиядә моны эшләгән кеше юк иде әле, алдагы 10-15-20 ел эчендә беркем эшләмәс тә, мөгаен. Стандартларны кабул иттек һәм безнең мәдрәсәләр узган ел сентябрь аенда яңача эшли башлады. Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге барлык мәдрәсәләрдә аудит уздырды. Әлбәттә, бар да шома гына, җиңел генә бармый, без моны көткән идек инде, чөнки беренче ел бит. Җитмәсә, профессиональ кадрлар, укытучылар җитми.Эш барышында барлык проблемаларны ачыклыйбыз.

**– Бүгенге көндә республикада яңа мөселман уку йортлары ачарга ихтыяҗ бармы?**

– Юк дип уйлыйм. Безгә хәзер укытуның сыйфатын яхшырту өстендә эшләргә кирәк. Татарстанда хәзерге вакытта 1500 мәчет бар, ел саен 25 мәчет төзелә. Казан губернасында 6 меңгә якын мәчет булган, шуңа омтылырга була. Әмма хикмәт санда да түгел. Мәчетләребез бүгенге көндә ничек эшли? 50 мәчеттә бөтенләй имам юк, 880 мәчетнең имамының берниндиде дини гыйлеме юк – менә проблема кайда? Әлбәттә, мәчетләрне төзүне дәвам итәргә кирәк, районнарда яңа мәчет төзү уе туа икән, берәрсе изге нияттән мәчет төзергә җыена икән, ул шуны да истә тотсын – мәчеткә имам да кирәк, аны карарга, хезмәт хакы түләргә кирәк, ул кайдадыр яшәргә тиеш. Димәк, бюджетка имам өчен йорт һәм имамның хезмәт хакын да салырга кирәк.

Бик күпләр төзеде мәчетне, ачкычын кемгәдер тапшырдылар да шуның белән мәчет турында оныттылар. Болай эшләү дөрес түгел.

Күптән түгел без мәчет каршындагы курсларда аттестация уздырдык. Ул курсларда 30 меңгә якын кеше укый,димәк,мәдрәсәләргә дә эш бар, укытыр кеше күп әле. Әйткәнемчә, 880 мәчетнең имамының дини белеме юк. Башка, бераз борчулы статистика да бар – имамнарның 15 процентының яше 80 не узган. Алар булганда, безнең авыл мәчетләре үзебезнең дини тәгълимат традицияләрен сакланыр әле, әмма аларга алмаш турында да уйларга вакыт.

Ә ни өчен 50 мәчетнең имамы юк? Бу гадәттә республиканың иң ерак почмакларындагы кечкенә генә авылларда шулай, анда дини уку йортын тәмамлаган яшьләрнең барасы килми, ара ераклыгы, торыр урын, хезмәт хакы булмау һәм башка проблемалар куркыта. Әмма мәчет бар икән, димәк, мәхәллә бар, алар имам турында бергәләп уйлашырга тиеш. Авылдагы яшь бер пенсионерны укытып кайтарырга була. Менә без шушы юнәлештә эшләргә тиеш.

**– Болгар ислам академиясе, һичшиксез, өммәтебез тормышында бик мөһим вакыйга булачак. Академия ачылу һәм аның эшчәнлеге республика дини мәгариф системасы структурасына, аерым алганда, Россия ислам институтының укыту программаларына йогынты ясамасмы?**

– Болгар ислам академиясе – ислам мәгарифе системасындагы дүртенче баскыч: мәчет каршындагы курслар, урта-һөнәри уку йортлары, Россия ислам институты... РИИ бакалавр программасын тормышка ашыра, дөньяви фәннәр – теология, лингвистика, икътисад юнәлешендә исә без магистр программасы буенча эшлибез. Болгар ислам академиясе тулысынча дини уку йорты булып, аның эшчәнлеге үзебезнең дини тәгълимат мәктәбен торгызуга юнәлтеләчәк. Аны тәмамлап чыгучылар магистр, шәригать, ислам фәннәре докторы дәрәҗәләрен алачак. Без аны халыкара стандартлар буенча эшләүче вуз итеп күз алдына китерәбез. Эре чит ил вузлары укытучылары җәлеп ителәчәк, шунлыктан шәригать фәннәре гарәп телендә укытылачак. Бу – академиядә татар теле укытылмаячак, татар ислам дине мирасы өйрәнелмәячәк дигән сүз түгел, әлбәттә. Студентлар магистрлык, докторлык диссертацияләрен гарәп телендә язачак. Таләпләр бик зур, шунлыктан без Казанда, Россия ислам институты базасында Әл-Әзһәр университетының гарәп телен өйрәнү үзәген ачарга җыенабыз. Минем уемча, Болгар ислам академиясе эшли башлагач, бездә мөселман мәгарифе системасы яңа баскычка күтәреләчәк.

**– Болгар ислам академиясе тулы куәтенә эшли башлагач, чит илләрдә белем алырга ихтыяҗ бетәр дип уйлыйсызмы?**

– Бу конкуренциягә сәләтлелектән торачак. Мин, мәсәлән, үзебезнең РИИны тәмамлап чыккан белгечләрне көчләп Болгар ислам академиясенә җибәрә алмыйм бит инде, чөнки аларның үзләре теләгән уку йортында укуларын дәвам иттерергә хаклары бар. Хәзер Әл-Әзһәрдә белем алырга мөмкинлек тудырылгач – бигрәк тә. Шуңа күрә белгечләрне ике диплом белән чыгару мөмкинлеген карарга кирәк, дип саныйм. Мин Карауин университетын тәкъдим итәр идем. Болгар ислам академиясенең магистр дипломын беренче елны ук белмәскә дә мөмкиннәр. Ә менә бер үк вакытта Болгар ислам академиясе һәм Карауин университеты магистры дипломын алса, ул чакта хәл башка. Укырга керергә теләүчеләр дә күбәер, академиянең үзенә дә дөньяның бердәм мөселман мәгарифе мәйданына чыгарга җиңелрәк булыр, дип уйлыйм.

# «РОССИЯ МӨСЕЛМАННАРЫНЫҢ БОРЫНГЫ



Россия һәм Татарстан мөселманнарының саны арта барган саен сыйфатлы белем бирү системасын булдыру кирәклеге турындагы мәсьәлә актуальрәк була бара. Россиядә ислам гыйлемен бирүче вузлар байтак булса да, хәзергә кадәр халыкара стандартларга туры килә торган мәгариф учреждениесе юк иде әле. Болгар ислам академиясе әнә шундый уку йорты булырга тиеш. Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең уртак проекты булган Болгар ислам академиясе турында матбугатта күп язылды, сәясәт эшлеклеләре һәм дин әһелләре дә ул хакта күп сөйләде, бу язмада без шушы проектка кагылышлы барлык мәгълүматны туплап бирергә булдык.

2015 елның җәендә Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Болгар ислам академиясен ачу тәкъдиме белән чыкты. Мөселман лидерларының идеясен РФ Президенты Владимир Путин да хуплады. Ул, яңа учреждение Россия мөселманнарының борынгы рухи һәм фәнни үзәген торгызырга ярдәм итәчәк, дип билгеләп үтте. «Бу академия Россия ислам галимнәренең, сессиягә җыелып, дин тәгълиматының катлаулы сорауларын хәл итү урыны булыр, дип уйлыйбыз. Академияне төзүнең актуальлеге дөньяда бүген бара торган сәяси вакыйгалар белән дә бәйле», – дип хәбәр ителде Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте хәбәрендә.

Соңрак, 2015 елның 4 ноябрендә, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Болгар ислам академиясен төзү турындагы Указны имзалады. Документта: «Бу карар традицион дини кыйммәтләрне саклау һәм үстерү, конфессияара һәм милләтара тынычлыкны һәм килешүне ныгыту максатыннан кабул ителде», – диелә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2016 ел, 25 март карары белән Болгар ислам академиясен төзүгә кагылышлы чаралар планы әзерләп расланды. Шул ук вакытта 2016 елның 21 маенда – Идел буе болгарлары ислам динен рәсми кабул иткән көнне академия төзеләчәк урында нигез ташы салыначагы мәгълүм булды. 2016 елның 4 апрелендә «Болгар ислам академиясе» югары дини белем бирүче мөселман дини оешмасы Бердәм дәүләт реестрында теркәлү узды. Әлеге оешманы гамәлгә куючылар – Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Азан» радиосына биргән интервьюсында: «Болгар ислам академиясе Россиякүләм һәм халыкара дәрәҗәдәге дини-белем бирү һәм рухи-мәгърифәт үзәге булачак», – дип белдерде. Академиягә методик яктан Казан федераль университеты ярдәм күрсәтәчәк. Шулай ук академиянең Әл-Әзһәр (Мисыр), Карауин (Марокко) университетлары, Иордания, Сүрия һәм башка чит илләрнең мәшһүр уку йортлары белән хезмәттәшлек итү мөмкинлеге дә карала.

Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» республика фонды җитәкчесе Минтимер Шәймиев «Милләт, төбәк һәм цивилизация яссылыгында мөселман дини тәгълиматы» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференциядә ясаган чыгышында болай диде: «Минем карашка, академиянең төп бурычы – XVIII–XX гасыр күренекле татар дин тәгълиматчылары үрнәгендә тирән белемле, абруйлы ислам дине галимнәрен тәрбияләп үстерү».

Проект буенча, уку бинасы Ак мәчеттән көньяк-көнчыгыштарак төзеләчәк. Академиянең төп корпусында фәнни-белем бирү үзәге урнашачак. Биредә югары профессиональ (магистратура, докто-



# РУХИ ҺӘМ ФӘННИ ҮЗӘГЕ ТОРГЫЗЫЛАЧАК!»

рантура) һәм өстәмә белем алырга мөмкин булачак. Барлыгы биш кафедра – ислам икътисады һәм хокукы; Коръән, сөннәт һәм дин тәгълиматы; менеджмент һәм дәүләт-динара мөнәсәбәтләр; гарәп теле һәм әдәбияты; татар теле һәм әдәбияты кафедралары ачу планлаштырыла. Биредә үк Голәмалар шурасы, Бөтенроссия ислам китапханәсе, Эксперт шурасы, Татар ислам дине тәгълиматчылары мирасын өйрәнү үзәге урнашачак. Академия үз эшен быел көздән үк башлап җибәрер дип планлаштырыла.

Болгар ислам академиясен тәмамлаучылар, партнер-вузлар белән килешү нигезендә, ике диплом алып чыгачак. Академия тәмамлаучылар диссертацияләрен бары тик гарәп телендә генә яза. Татарстанда Болгар академиясе бинасын төзү өчен хәйрия фонды булдырылды. Төзелешкә 1 млрд сум акча тотылачак. Академия бинасының проектын «Татинвестгражданпроект» оешмасы эшләгән.

***

Болгар ислам академиясендә октябрь - март айларында алты айлык курслар узды. Анда имамнар Изге Коръәнне тавыш белән укырга өйрәнделәр, ислам фәннәре буенча гыйлемнәрен ныгыттылар. Соңыннан Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин биредә гыйлем туплаган 27 имамга дипломнар тапшырды. Әлеге тантаналы чарада имамнарга гыйлем биргән Амман халыкара университеты профессоры Габдурразак Әс-Сәгъди, Төркиядән килгән коръәнхафиз Габдулла Фалай һәм башка дин әһелләре катнашты.



**Владимир Путин, Россия Федерациясе Президенты:**

«Мөселман яшьләренең традицион ислам кыйммәтләрендә тәрбияләнүе; чын ислам белән бернинди уртаклыгы булмаган, чит карашларны безгә көчләп тагуларны вакытында туктату мөһим. Ассызыклап әйтәм: дәүләт алга таба да илебезнең мөселман тәгълиматы мәктәбен, үзебезнең дини белем бирү системасын торгызуда ярдәм итәчәк. Белүегезчә, минем тарафтан Татарстан җитәкчелеге һәм мөселманнарның диния нәзарәтләренең Болгар ислам академиясен төзү тәкъдиме хупланды. Шулай итеп, Россия мөселманнарының борынгы рухи һәм фәнни үзәге торгызылачак» (2015 елның 23 сентябрендә Мәскәү җамигъ мәчетен реконструкциядән соң ачканда ясаган чыгышыннан).

**Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:**

«Рухи тамырларыбызның нәкъ менә Болгарда булуын, нәкъ менә биредә үзебезне бөек мөселман цивилизациясенең бер өлеше итеп аңлавыбызны исәпкә алып, Ислам академиясен биредә төзесәк – дөрес булыр. Болгар янә Россия һәм халыкара дәрәҗәдәге йогынтылы үзәкләрнең берсе булырга тиеш» (2015 елның 8 октябрендә Болгарда узган «Милләт, төбәк һәм цивилизация яссылыгында мөселман дини тәгълиматы» дип аталган халыкара фәннигамәли конференциянең пленар утырышында ясаган чыгышыннан)

**Минтимер Шәймиев, ТРның Дәүләт Киңәшчесе:**

«Болгар ислам академиясе Россияне генә түгел, бөтен БДБ илләрен дини кадрлар белән тәэмин итә алырлык уку йортына әверелер. Академия эшчәнлеге татар ислам дине галимнәре мирасын саклау һәм үстерү, дини белем бирүнең дәрәҗәсен күтәрү, радикаль карашларга каршы тору, мөселман өммәтен хәнәфи мәзһәбенә нигезләнгән традицион ислам кыйммәтләре принципларында берләштерү кебек актуаль мәсьәләләрне чишәргә мөмкинлек бирер» (2015 елның 8 октябрендә Болгарда узган «Милләт, төбәк һәм цивилизация яссылыгында мөселман дини тәгълиматы» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференциянең пленар утырышында ясаган чыгышыннан)

**Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан мөфтие:**

«Болгар һәрвакыт татарларның гына түгел, илебезнең бөтен мөселман халыклары өчен ислам һәм ислам мәгарифе башкаласы булып торды. Болгарда ислам академиясе төзелү – тарихыбызның дәвамы да, аның торгызылуы да» (2016 елның 29 апрелендә «Яңарыш» фонды попечительләр советының киңәйтелгән утырышында ясаган чыгышыннан)



# БОЛГАР ДӘҮЛӘТ ТАРИХИ-АРХИТЕКТУРА МУЗЕЙ ТЫЮЛЫГЫНДАГЫ «БОЛГАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ. МЕҢЬЕЛЛЫККА СУЗЫЛГАН ЮЛ» ИНСТАЛЛЯЦИЯСЕ



2013 ел Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында «Болгар цивилизациясе» музееен ачу белән тарихка кереп калды. Бу дөньякүләм әһәмияткә ия булган тарихи объектны реконструкцияләү, реставрацияләү һәм саклау буенча эшләнгән проектның катализаторы Татарстанның беренче Президенты М.Ш. Шәймиев җитәкләгән ТРның Тарихи һәм мәдәни ядкярләрен яңадан торгызу республика фонды булды. Музейның концепциясен Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты Казан (Идел буе) федераль университеты, А.Х. Халиков исемендәге археология институты белән берлектә эшләде һәм гамәлгә ашырды. Иҗат төркемендә галимнәр Р.Р. Хәйретдинов, А.Г. Ситдыйков, Д.Г. Бугров, рәссамнар: И.Н. Артамонов, А.П. Леухин, Ф.Р. Вәлиуллин, Р.С. Шиһабетдинов, И.В. Щетининнар.

«Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкка сузылган юл» экспозициясе Идел ярларының биек ландшафтына тәңгәл килерлек урында, алты катлы бинаның ике этажын алып тора. Болгарга керү юлында тантаналы «капка» ролен үтәүче монументаль архитектура корылмасы елга вокзалы белән музей функциясен берләштерә. Аның бурычы бирегә килүчеләрне Болгар шәһәрчеге территориясенә күтәрелүне тәэмин итү генә түгел, ә иң мөһиме – бөек цивилизациянең тарихы белән таныштыру.

Гадәттә рәссамга экспозиция төзегәндә объектларны бизәү (витриналар, стендлар, экспликацияләр, диварларны декоратив-эчтәлекле бизәү һ.б) кебек икенче пландагы эшләр бирелә. Ә монда төрле элементлардан торган заманча инсталляция (табигать объектлары, текстлы, визуаль, видео мәгълүматлар) иҗади музей төзелеше өлкәсендә өр-яңа сүз.

Бу экспозициядә төрледән-төрле стильдәге объектлар, тарихи документлар, археологик артефактлар тулаем бер визуаль спектакль тудыра. Тамашачы үзен картиналардагы тарихи вакыйгаларның үзгәреп, алмашынып торган үзәгендә кайнаган кебек хис итә. Экспозициянең барлык состав өлешләре дә үзара тыгыз элемтәдә, һәр аерым элемент бербөтенлек принципы буенча хәл ителгән. Витриналарның композициясе, декоратив монументаль паннолар, мәгълүматка бай интерактив панельләре арт-объектлар итеп күзаллана, әмма шул вакытта алар барысы да аерым сәнгать әсәренә хас булган характерлы билгеләре белән мега-инсталляция элементларын тәшкил итәләр.

«Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкка сузылган юл» композициясе өч бүлектән тора: «Төрки цивилизациянең чыганаклары», ««Борынгы Болгар: шәһәр тормышы», «Болгарны ачу һәм өйрәнү тарихы». Өченче катта урнашкан мәйданда Болгар цивилизациясенең барлыкка килүе һәм Казан ханлыгы чорына кадәр үсеше тасвирлана. Дүртенче катта урнашкан композициядә Бөек Болгарның Алтын Урда чорындагы күтәрелешенә кагылышлы сюжетлар, борынгы Болгарны ачу һәм өйрәнү тарихы.

Инсталляция авторларының бәхәссез уңышы – тамашачыларда билгеле бер эчтәлекле контекст тудыруга ярдәм итүче пластик чараларны төгәл сайлау. Мәсәлән, «Төрки цивилизациянең чыганаклары» бүлегенең темасын ачу өчен дала культурасы образы кулланылган. Шуңа да экспозиция тарихи археологик артефактлар, борынгы карталарның фрагментлары ярдәмендә формалашкан, ә гомуми пластика стилистикасы петроглифлар белән билгеләнә. Композициянең бер өлеше стена буенча тезелеп киткән һәм анда «картографик кыйпылчыклар», пыяладан эшләнгән монументаль композицияләр, күләмле картиналар, сурәтләре алышынып торучы видео панельләр, асылташлар бер җепкә тезелгән кебек, чиратлаштырып урнаштырылган. Монда композиция төзүнең мөселман сәнгать дөньясы өчен хас булган универсаль принципы кулланылган – һәр энҗе бөртеге дә кадерле, әмма алар бербөтеннең аерым бер өлешен тәшкил итәләр. Экспозиция декоратив элементларны гына бәйләп калмый, ул хронологик тәртиптә төзелгән һәм тамашачыны тарихи вакыйгалар буйлап сәяхәткә алып китә. Шул ук вакытта периметр буенча төзелгән композиция болгар цивилизациясенең матди байлыгына багышланган залның «кыршавы» ролен дә үти. Үзәк композиция үзе өч өлештән тора. Беренчесе борынгы төзелеш эзләрен хәтерләтүче экспозицион платформадан гыйбарәт. Андагы горизонталь һәм вертикаль витрина блокларыннан төзелгән корылмалар, табигый тере дөньяны тою хисен тудыра.

Объектларны төрле яктан тамашачыга тулаем күрсәтүдә утларның роле аеруча зур. Композициянең икенче өлешендә видео-проекцияле тугыз метрлы экран урнаштырылган. Ул экспозициягә динамик төсмер бирә, күзаллау мөмкинлекләрен арттыра. Өченче өлешне форматлаштыручы төп элемент булып декоратив плафон тора. Ул – күк символы, анда көнчыгыш миниатюр тасвирый сәнгатенең сюжетлары аша җир ландшафтының катлаулы мозаикасы чагыла. Залның бизәлешендә җирне хәтерләтүче төсләр (охра, умбра) кулланылган. Биредә колористик төзелеш бик мөһим, ул барлык цивилизацияләргә дә башлангыч көч бирүче тарихи чыганакларыбызга ишарә итә.

«Борынгы Болгар: шәһәр тормышы» бүлегендә цивилизациянең чәчәк ату, рухи күтәрелеш символы булган яшел төс өстенлек ала. Декоратив панно охра колоритында эшләнгән, әмма яшел фонда ул «алтын» төсмерен ала. Монда да ике өлешле композиция схемасы кулланыла – периметр буенча һәм үзәктә. Периметр сәнгать реконструкцияләре, предметлы композицияләр һәм тематик бүлекләр буенча ритмик бәйләнештә булган декоратив-монументаль паннолардан тора. Әгәр өченче катта инсталляция образының нигезен дала культурасы тәшкил итсә, монда исә үзенең бөтен тормыш-көнкүреше белән көнчыгыш шәһәре образы гәүдәләндерелгән. Биредә бөек Болгар монументаль «планографиясе» белән тематик бүлекләр аша танышырга мөмкин. Тамашачы бер күренештән икенчесенә күчә, Бөек Болгарга багышланган китап битләрен ачкан кебек, аның күз алдында шәһәр тормышы төрле яклап ачыла – дәүләт һәм дин тормышы, шәһәр халкы, аның көнкүреше, һөнәрләре һ.б.

Залның үзәк өлеше турыпочмаклы подиум-постамент рәвешендә. Болгар дәүләте «бинасының» логик һәм бербөтен төзелешен символлаштыру өчен, подиум залның архитектура колонналары белән пластик рәвештә бәйләнгән. Подиумның почмаклары, билгеле бер символик мәгънә бирү өчен, болгар шәһәрчеге һәйкәлләренең декор композициясе элементлары белән тоташтырылган. Постамент мәйданчыгына колонна почмаклары буйлап килүче, борынгы шәһәр силуэтларын чагылдырган, декоратив пыяла панель-пәрдә нокта куя. Пыяла аңлы рәвештә кулланылган. Ул инсталляция витриналары һәм сәнгать эшләнмәләре арасында стилистик бөтенлек булдырырга ярдәм итә. Подиумда урнаштырылган алты горизонталь витрина аның дәвамы буларак кабул ителә һәм безне борынгы шәһәрнең үзәк мәйданында итеп тояргә мөмкинлек бирә. Тамашачы үзен дөньяның төрле почмакларыннан килгән товарларга бай булган базарда йөргән кебек хис итә. Моңа ирешергә витриналарның эчендәге халыклар һәм мәдәниятләрне чагылдыручы образлары белән бергә урта гасырлар картасы да ярдәм итә. Яшел төс бу очракта да үз максатына ирешә, төрле витриналар һәм декоратив пәрдәләр ярдәмендә келәм-подиумга әйләнеп, болгар шәһәрчегенең макеты урнашкан композиция үзәгенә тантаналы төсмер өсти.

«Болгарны ачу һәм өйрәнү» дип аталган өченче бүлектә Болгар шәһәрчегенең тарихи планда эшләнгән күренешләре урын алган, аның өйрәнелү тарихы хронологик тәртиптә бирелгән. Композиция горизонталь витриналар һәм коллажлы инсталляцияләрдән тора. Витриналардагы экспонатларның дәвамын археологик рельеф катламнары аша

# БАБАЛАРЫБЫЗ ЮЛЫ БЕЗГӘ ҮРНӘК

## 21 май – Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми кабул иткән көн

**ҖӘЛИЛ ХӘЗРӘТ ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые,**
**Балтач районы имам-мөхтәсибе**



Болгар бабаларыбыз ислам динен кабул иткәнче дә Болгар җирендә мәчетләр эшләп килгән, мәчет-мәдрәсәләр булган. Әмма ул дин рәсми рәвештә дәүләт дине булып игълан ителмәгән була әле. Милади белән 922 нче елны, һиҗри белән 310 елның 16 мөхәррәмендә безнең Болгар бабаларыбыз үз ирекләре белән ислам динен рәсми рәвештә кабул итеп алганнар. Дәүләт дине итеп, дәүләт дәрәҗәсендә. Йөз елга 4 буын алышына, дип исәпләсәк, моннан 44 буын элек безнең бабаларыбыз бер Аллаһыны гына зурлап, Аллаһыдан башка затка коллык кылмый торган ислам динен тота башлаганнар. Шуның белән алар гүзәл дәүләт төзегәннәр. Илләре бөтен дөньяга мәшһүр булган, тормышлары алга киткән. Һәм алар бер Аллаһыга гына кол булып яшәгәннәр. «Шешә»гә дә, бүтән бозыклыкка да кол түгел. Аларның чисталыклары, пакълекләре турында елъязмачылар да бик күп итеп язып калдырганнар.

Аллаһы Раббыбыз Коръәндә әйтә: «Берәү Миңа якын булган саен, Мин аны сынармын, ул сынауны уңышлы үткән саен, ул Миңа якынрак булыр», – ди. Безнең халкыбызга да бу еллар эчендә дин буенча, күп сынаулар үтәргә туры килгән. Барлык олы кеше диярлек укый-яза белгән, динен тоткан. Шушы дәүләттә Аллаһының кануны яшәгән. Ислам динен кабул итеп 300 ел үткәч, монгол яулары килеп җитә. Берүзе күп еллар монгол яуларына каршы торганнан соң, дәүләт җимерелеп, монгол яулары кул астында кала. Әмма иманнарын сатмыйлар безнең бабаларыбыз, иманнарында нык калалар. Берсе дә «шешә» колы да, аракы колы да булмый, намазын да куймый. Алар үзләрен басып алган халыкны үзләренең мәдәниятләре белән, үзләренең алга киткән булулары белән, үзләренең мәгърифәт өлкәсендәге алдынгылыклары белән сокландыралар. Ислам динен кабул итүнең бу очракта да әһәмиятле роле күренеп тора. Яу белән килгән кешеләр дә ислам кануннары буенча яши башлыйлар.

Һәм тагын ничәмә еллар үтә. 1552 нче елны ислам кануннары буенча яши торган шушы дәүләтне рус гаскәрләре яулап ала. Бу вакытта да динебез өчен, милләтебезне саклап калыр өчен аяусыз көрәш бара. Шушы вакытта телләрен, диннәрен, мәгърифәтләрен саклап калыр өчен һәр дүрт татарның өчесе шәһит китә. Халык бу юлы да иманына тугры кала. Намазларын куймыйлар, «шешә» коллары булмыйлар. Руслар хәтта шундый законнар чыгаралар, һәрбер татар авылында аракы сата торган кибетләр ачтыралар. Татар авыллары гына түгел, Казан губернасындагы удмурт, чуаш, мари авылларыннан – 800 авылдан патшага үтенеч-хатлар китә. Аракы сата торган кибетләрне ябыгыз, безгә алар кирәк түгел, диләр. Шундый вакытларда да бер Аллаһыны гына тану дәвам итә. Кеше намаздан читләшү турында уйламый да.

Мин берничә ел элек җыелган олылардан: «Әти-әниләрегез намазларын калдырса, нишлиләр иде?» – дип сорадым. «Намазларын укый алмасалар, елыйлар иде. Ничек булса да, калган намаз итеп үтәргә тырышалар, качып булса да укыйлар иде. Безнең әти-әниләребез шулай яшәде», – диделәр. Бүгенге көндә кайберәүләребез әти-әни, әби-бабай йоласын ашка йөрү дип кенә аңлый. Йә булмаса, мәет күмүдә катнашу гына дип беләләр. Әти-әни йоласы – моннан унбер гасыр элек безнең бабаларыбыз кабул итеп алган дин ул, ислам дине. Аның нигезе – намаз. Һәм ул – Аллаһ хөкеме буенча яшәү. Биш вакыт намаз укый алмагач, иман нык түгел, дигән сүз. Бабаларыбыз бездән риза булсын, алар тоткан динне дәвам итик, дисәк, без бер Аллаһыга гына табынырга, хәрамнан ерак торырга тиеш, намазларыбызны торгызырга тиешбез. Коръәннең «Әл-Бәкара (Сыер)» сүрәсенең 3 нче аятендә болай әйтелгән: «Иман китергән кешеләр, күрмәгән килеш, күргән шикелле Аллаһыга табынырлар, алар намазларын торгызырлар. Минем биргән нигъмәтләремнән миңа өлеш чыгарырлар». Намазларын укырлар гына түгел, намазларын торгызырлар, диелә. Димәк, үзе намаз укый, гаиләсен шуңа чакыра, күршеләрен шуңа чакыра. Намазга өнди. Намаз укучылар күбрәк булсын дип тырыша.

Аллаһы Раббыбыз бернәрсә дә бирмичә, бездән бер әйбер дә сорамый. Акыл биргән икән, ул безне намаз белән йөкли. Авырыйбызмы, эшебез бармы, тормыш-көнкүрешебез бик тыгызмы безнең, акылыбыз бар икән, безгә йөкләнгән биш вакыт намазны – фарыз тиешле гыйбадәтне беркем дә ала алмый. Әгәр без шушыны танымыйбыз икән, ата-баба йоласын дәвам итү түгел бу. Без, әби-бабайларыбыз шикелле яшибез, дип әйтә алмыйбыз. Аллаһы Раббыбыз сәламәтлек биргән икән, без елга бер ай ураза тотарга тиеш. Авырыйсың икән – фарыз түгел ул сиңа. Байлык биргән икән, без аның зәкятен чыгарырга тиеш. Аның 40 тан бер өлеше безнеке түгел, без аны Аллаһ ризалыгы өчен тотарга тиеш. Һәм без аракыдан ерак булырга тиешбез. Аракы, наркотик ише нәрсәләр турында пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа: «Һәр исерткеч – хәмердер, һәр хәмер – хәрамдыр», – диде. Башны аңгырайта торган һәрнәрсәне без хәрам дип белергә тиеш.

Һиҗри белән 310 нчы елны безнең бабаларыбыз үзләренә яшәү рәвешен сайлап алдылар һәм 1917 нче елга хәтле шулай гомер кичерделәр. Аларны үлем белән куркытып, асып та карадылар, сөргенгә дә куып котылмакчы булдылар, әмма намазларын ташлата алмадылар. 17 нче елга чаклы дөньяда иң мәгърифәтле милләтнең берсе – татар халкы иде. Россия империясенең 70 процент сәүдә әйләнеше татар сәүдәгәрләре кулында булды. Чөнки алар аек, исерек түгел иде. Чөнки берәү дә исерек кешегә малын тапшырмый. Исерек кулына мал керсә, ул таралып бетә.

*Дәвамы 12 нче биттә*

# «БОЛГАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ. МЕҢЬЕЛЛЫККА СУЗЫЛГАН ЮЛ» ИНСТАЛЛЯЦИЯСЕ

*Ахыры. Башы 10 нчы биттә*

чагылучы сәнгать «тасвирламаларында» күрергә була.

Һәрбер объект, экспозицияләр авторларның бергәләп, иҗади эшләү процессында туган. Монда һәммә деталь, фрагмент, композиция бөтен яктан да уйланылган – тарихилык, сурәтләрне кабул итү дәрәҗәсе, ассоциацияләр тудыру сәләте. «Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкка сузылган юл» инсталляциясе тарихи материалны сәнгати тасвирлау чаралары аша чагылдыруның гүзәл үрнәге, бер максат белән янып эшләүче команданың фидакарь хезмәт нәтиҗәсе. Билгеле, бу – дөньякүләм танылган музейлар дәрәҗәсендәге мәдәни корылма безнең горурлыгыбыз.

ИКОМОС (международный совет по сохранению памятников и достопримечательностей) хисабында Болгар цивилизациясе музее хакында болай диелгән: «Он обеспечивает соответствующее и высококачественное представление территории объекта, уже решительно направленное на предполагаемую Выдающуюся Всемирную Ценность г. Болгар…»

**«Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкка сузылган юл» инсталляциясенең авторлар төркеме быел Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек дип табылды.**

**Рауза Солтанова,**
сәнгать фәннәре кандидаты,
«Фәнни Татарстан»

# РАМАЗАН ВӘГЪДӘЛӘРЕ



*** Рамазан аеның беренче 10 көне** – Аллаһ рәхмәтенә ия булу вакыты. Аллаһ рәхмәтенә ирешү исә бик тә мөһим нәрсә, чөнки бу – кеше бәхет иясе булды дигән сүз. Безнең ниндидер уңышка ирешүебез, эшмаксатларыбызның тормышка ашуы фәкать Аллаһ рәхмәте һәм ярдәме белән бәйле.

*** Рамазан аеның икенче 10 көне** – гөнаһларның гафу ителү көннәре (мәгъфирәт). Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер кеше килә дә фәкыйрьлеккә, акча җитмәүгә зарлана. Пәйгамбәр аңа: «Аллаһтан гөнаһларың өчен гафу үтен», – дип киңәш бирә. Икенче кеше килеп: «Хатыным белән ничә ел торабыз, әмма балаларыбыз юк», – дип зары белән уртаклаша. Мөхәммәд галәй-һиссәлам аңа да: «Тәүбә-истигъфар кылыгыз, гөнаһлар өчен Аллаһтан гафу үтенегез», – дип җавап бирә. Өченче кеше килеп Пәйгамбәргә: «Безнең җирлектә корылык, инде күп вакыт яңгыр яумый», – дип әйтә, дүртенче кеше исә: «Бездә яңгыр ява, ләкин уңыш юк», – дип зарлана. Аларга да Мөхәммәд пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһтан гөнаһларыгыз өчен гафу үтенегез», – дип нәсыйхәт кыла. Моны ишеткән сәхабәләр аптырап сорыйлар: «Йә Аллаһның рәсүле, дүрт кеше дүрт төрле мәсьәлә белән мөрәҗәгать итте, әмма барысына да бер үк киңәш бирдең...». Мөхәммәд пәйгамбәр иярченнәренә болай дип җавап бирә: **«Бу мин түгел, моны Аллаһы Тәгалә Коръәндә шулай киңәш итә...»** (« Һуд», 11:3,52).

*** Рамазан аеның өченче 10 көне** – тәмуг утыннан котылу көннәре. Бу вакыт уразаның тәмамлану чоры. Кем дә кем шул көннәрне тәкъвалык белән гыйбадәттә үткәрсә, аның җәһәннәм утына керүгә сәбәпче булган гөнаһлары ярлыканыр һәм рамазан ае ахырына ул гөнаһсыз, пакь җанлы бала кебек булыр. Рамазанның ахыргы ункөнлегенә мең айдан да хәерлерәк булган Кадер кичәсе туры килә. Игътикяф гыйбадәтенең дә нәкъ менә шушы чорга билгеләнүендә зур хикмәт бардыр.

**Ришат хәзрәт Курамшин,**
Кукмара мәдрәсәсе директоры

# БАБАЛАРЫБЫЗ ЮЛЫ БЕЗГӘ ҮРНӘК

*Дәвамы. Башы 11 нче биттә*

1929-1930 еллардан башлап күп мәчетләр җимерелде, муллалар сөргенгә куылды, 40 меңләп мулла үтерелде. Дин дәүләттән тыш дип игълан ителде. Аракы эчү йолага әйләнде. Нәрсә эшләсәң дә, ни уздырсаң да аракысыз булмый. Намазны аракыга алыштыргач, ул халык элекке милләт түгел инде. Ул халык – хайван дәрәҗәсендә. Аңа Аллаһының хөкеме дә – хайванча яшәү. Ул бозылуга, бетүгә таба бара. Үзен-үзе бетерүгә юл тота. Чөнки Аллаһы Раббыбыз Коръәндә әйтте: «Минем куйган кануннарым буенча яшәмәгән халык бетүгә таба бара», – диде. «Әл-Мөлек (Патшалык)» сүрәсенең 18 нче аятендә, динен ташлаган бер генә халык та Җир йөзендә яши алмый, диелә.

Бүген дин дәүләттән аерылган, дин дәүләттән башка яши ала ул. Әмма дәүләт диннән башка яши алмый. Бер дәүләтнең дине юк икән, ул дәүләт юкка чыга. Ул, әлбәттә, 50-60 ел яшәргә мөмкин. Бу вакыт дәүләт булып тору ул – тарих өчен юк дәрәҗәсендә. Бу – кеше гомере генә. Мондый дәүләт үз бозыклыгы белән үзе бетә. Чөнки Аллаһы Раббыбыз әйтте: «Динен ташлаганнардан Мин сүтәр өчен төзеттерермен», – диде. Кирәкмәгән эш эшләтермен», – диде. Халык ач-ялангач булды, халык акчасына танклар, зур-зур техникалар төзелде. Шулар сүтелә хәзер. Сүтәр өчен төзегән булганбыз. Берсе дә тормышка, эшкә ярый торган түгел. Бу – динсез яшәүнең бер күренеше, мисалы булып тора. Безнең гасырның 40 нчы, 50 нче елларында нефть хәлиткеч чималга әйләнде ки, нефте булган дәүләтләр гөрләп алга киттеләр, дөнья күләменә чыктылар, халыкның яшәү рәвеше алдынгы урыннарга күчте. Динсез дәүләтләрдә, нефть чыкса да, бернәрсәгә дә ирешмәделәр. Гарәп Әмирлекләрендә исә хәл башка. Анда яңа туган балага, нефть биргән байлык аркасында, таныклык белән бергә акча салынган саклык кенәгәсе тоттыралар. Согуд Гарәбстанында да һәр балага кенәгә бирелә. Һәм җирдән чыккан байлык, Коръән буенча, халыкныкы санала. Нефтьтән күпме керем булса, җан башына автомат рәвештә күчеп бара.

Менә бу – Коръән кануннары белән яшәү үрнәге. Бездә дә нефть чыга, бездәге җирдә нәрсә төртсәң – шул үсеп чыга. Әмма бездә 44 буын элек кабул ителгән канун бозылган. Без бүген кирәкмәгән эш өчен, аракы өчен яшибез. Шуның белән бер-беребезгә мәшәкать-борчу тудырабыз. Шуңа күрә 60 яше тулган 100 ирнең 31е генә лаеклы ялга чыга, 69 ы пенсия яшенә җиткәнче үк үлә. Боларның бөтенесенә дә шушы аракы сәбәпче.

Менә бер көн – тәмәкегә каршы, икенче бер көн – наркоманиягә каршы көрәш көннәре. Бу яман чирләрне берәр көн көрәшеп кенә җиңеп булмый. Балаларга туганнан башлап аның хәрам икәнен аңлатырга кирәк. Балалар бакчасында да, мәктәптә дә, өйдә дә. Бүген аны ярамый торган, хәрам әйбер, дип сөйләп, икенче көнне үк эчеп утырсаң, бала күңелендә хәрам дигән хис уянмый. Безнең бабаларыбыз (аларга Аллаһның рәхмәте булсын) дөрес юлны сайлаганнар. Шуңа мәгърифәтле халык булып яшәгәннәр. Инде Аллаһы Раббыбыз безгә тагын мөмкинлек бирде. Мәчетләребез аякка басты, намаз укыган, дин тоткан өчен бернинди кысу, чикләүләр юк. Хөкүмәткә дә Аллаһның рәхмәте булсын, Аллаһы Тәгаләгә дә безнең мактау сүзләребез яусын. Бу, бәлки, Аллаһы Раббыбызның безне соңгы сынавыдыр. Инде дә шушы дөрес юлдан китә алмасак, милләт буларак без яшәүдән туктыйбыз. Әллә нинди декларацияләр кабул итсәк тә, суверенлыклар игълан итсәк тә, бабаларыбыз кабул иткән асылыбызга – исламга кайтмасак, яшәүдән туктыйбыз.

Ислам буенча яшәү ул – ашка йөрү, 3 се, 7 се, 40 ын үткәрү генә түгел. Ул – Аллаһыны тану, мәчеттә җәмәгать белән биш вакыт намаз уку, ураза тоту һәм хәмердән ерак булу. Менә шулай булганда ислам буенча, ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен саклап яшибез, дип әйтергә була. Без әби-бабаларыбызча яшибез, әби-бабаларыбыз алай эшләгән, болай эшләгән, дип бик күп сөйләргә яратабыз. Әмма алар намазларын бер дә куймаганнар, без иң беренче чиратта шуңа ирешергә тиешбез. Алар аракыдан ерак торганнар. Дуңгыз ите дә ашамаганнар. Балаларыбызны да шушылай итеп тәрбияләсәк, шәт, бабаларыбызның рухлары бездән риза булыр. Аллаһы Тәгалә каршысында да без иманлы бәндәләр булып, мөселман кешеләре булып, ата-бабаларыбызның динен, Аллаһы Тәгалә тарафыннан безгә иңдерелгән ислам динен тотучылар булып, ак йөз белән, Аллаһ насыйп итсә, дөньялыктан чын күңел белән ахирәткә барырбыз.

# РАМАЗАН АЕНЫҢ ФАЗЫЙЛӘТЕ

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә хәбәр бирә: «Әй, иман китергән кешеләр, сездән алдагы кавемнәргә фарыз булган кебек, сезгә дә ураза фарыз булды, уразаларыгызны тотыгыз, шәт, тәкъвалы булырсыз» («Әл-Бәкара (Сыер)», 2:183). Рамазан аенда һәр көн ураза тоту, ягъни таң яктылыгы җәелгән вакыттан башлап, кояш батканчыга кадәр ашамый, эчми һәм якынлык кылмый тору – балигъ һәм акыллы булган һәрбер мөэмин кешегә фарыз. Аллаһы Тәгалә әлеге аятьтә болай ди: «Сездән алдагы кавемнәргә фарыз булган кебек, сезгә дә ураза фарыз булды», ягъни безгә кадәр булган барча халык та уразалы булганнар, хәтта археологларның тикшерүләренә караганда, безгә кадәр уразасыз халык яшәмәгән, диләр.

Сәгыйть ибн Җөбәир әйтә: «Безгә кадәр исламның әүвәлге вакытында да уразаны кичтән алып икенче кичкә кадәр тоталар иде», ягъни безнеңчә әйткәндә бер тәүлек. Әмма инде шушы аять иңгәч, бу йола туктатылды. Шушы аятькә тагын күз салсак, Аллаһы Тәгалә әйтә: «шәт, тәкъвалы булырсыз», әмма ураза тотып, әлбәттә, тәкъвалы буласы димәгән! Чөнки кешенең үзеннән тора, һәртөрле гөнаһтан саклана аламы, гайбәттән, хәрамга күз төшерүдән, сүгенүдән, талашулардан һ.б.

Пәйгамбәребез әйтте: «Әгәр дә кеше бозык сүзләрдән, ялганнан, гайбәттән тыела алмаса, Аллаһы Тәгалә аның ашау-эчүне ташлавына мохтаҗ түгел». Шуңа күрә мөселман игелекле, күркәм әхлаклы, хәерле сүзле булырга тиеш.

Шулай ук Раббыбыз Сөбханә вә Тәгалә әйтте: «Рамазан ае бик шәриф ай, ул айда Аллаһыдан кешеләргә туры юлны күрсәтүче һәм һидаятьне ачык бәян кылучы Коръән индерелде. Сезләрдән рамазан аена ирешкән һәрберегез, әлбәттә, ураза тотсын!» (Аллаһының ураза тотарга биргән әмере: ирләргә, хатыннарга, яшьләргә, картларга, байларга, ярлыларга, патшаларга, гадиләргә, эшчеләргә, укучыларга һәм хәрбиләргә. Эшнең авырлыгы, тормышның мәшәкатьле булуы, балаларның күплеге, яшьләрнең мәктәптә яки югары уку йортларында укулары һәм бәлә-каза килүләр, ураза тотмаска гозер була алмыйлар. Фәкать ятып чирләгән, мәшәкатьле озын сәфәрдә булган, картлык зәгыйфьлегенә ирешкән, токтында булган һәм йөкле, хәезле хатыннар – болар гозерле булалар. Картлык зәгыйфьлегенә ирешкән кеше һәм сәламәтләнми торган чирле кеше, болар көчләре җитмәү сәбәпле ураза тотмыйлар һәм каза да кылмыйлар. Маллары булса, фидия бирәләр). Рамазан аенда берәү чирле булса яки мәшәкатьле озын сәфәрдә булса, ураза тотмасын, чирле кеше сәламәтләнсә, мосафир өенә кайткач, башка вакытта каза кылырлар. Аллаһ сезгә җиңеллекне тели, авырлыкны теләми һәм рамазан уразасын тутырып тотуыгызны һәм Аллаһ сезне туры юлга күндергәне өчен Аны зурлавыгызны тели, шаять, Аллаһыга шөкер итәрсез!»

Шушы аятьтән аңлашылганча, Коръән рамазан аенда иңә башлаган,



шуңа күрә рамазан аенда Коръән уку мөстәхәб һәм савабы да артыграк. Риваятьләргә караганда, барча илаһи китаплар нәкъ менә рамазан аенда иңгән. Забур китабы – алтынчы рамазанда, Тәурат китабы – уникенче рамазанда, Инҗил китабы – унтугызынчы рамазанда һәм Коръән китабы – егерме җиденче рамазанда. Әл-Багави дигән галим түбәндәге сүзләрне әйтте: «Дөреслектә, «Рамазан» дигән сүз «Рамдаа» дигән сүздән алынган, ягъни кыздырылган ташлар мәгънәсендә, чөнки алар кызу көндә ураза тотканнар».

Ул замандагы гарәпләр берәр айга исем бирергә теләгәндә, алар беренче чиратта вакыйгаларга яки фасылларга карый торган булганнар, әмма рамазан ае кызу көнгә туры килгәч, алар ул айга «рамазан» дип исем бирделәр.

Икенче бер галим әйтте: «Ул айны гөнаһларны яндырганга күрә рамазан дип атадылар».

Рамазан уразасы икенче һиҗри елда фарыз була. Ураза турында күп кенә хәдисләр риваять ителә: Әбү Һурайрадан риваять ителә, Пәйгамбәребез әйтте: «Рамазан ае кергәч, җәннәт ишекләре ачыла, җәһәннәм ишекләре ябыла, шайтаннар богауланыр», – диде. Шушы хәдистән аңлашылганча, рамазан аенда Аллаһының рәхмәте иңәр һәм шайтаннар бикләнер, богауланыр һәм ураза тотарга комачауламаслар. Күпләребезнең сизгәне бардыр, башка айлардан аермалы буларак, рамазан аенда ураза тоту аеруча җиңел һәм гөнаһлар да аз кылына. Хәдис дәвамында Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй хәерлегә омтылучы! Якынай Аллаһыга! Әй начарлыкка омтылучы! Тукта гөнаһыңнан! Аллаһ һәр төнне бер ураза тотучыны җәһәннәмнән коткарыр». Дәвам итеп Аллаһ әйтер: «Гафу сораучы бармы, гонаһларын гафу итәрмен! Берәр ихтыяҗың бармы, сораганыңны бирермен! Тәүбә кылучы бармы, тәүбәләрен кабул итәрмен! Һәм шушы мөрәҗәгать таң атканчы дәвам итәр. Һәм Аллаһ Тәгалә һәр көнне, һәр ифтар вакытында меңләгән ураза тотучы мөселманнарны җәһәннәм утыннан коткарыр» (Тирмизи).

Әй кардәшләрем! Шушы форсаттан мәхрүм кала күрмәгез! Чөнки тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез: «Ни үкенеч шул кешегә, рамазан үтеп китеп тә, гөнаһлары гафу ителмәсә», – диде.

Сәлмән Әл-Фәриси риваять итә, пәйгамбәребез шәгъбан аеның соңгы көнендә безгә вәгазь сөйләгәндә әйтәдер иде: «Әй кешеләр! Сезгә бөек ай якынлашып килә, ул айда мең айдан да хәерлерәк булган, Кадер кичәсе бар һәм Аллаһы Тәгалә бу айда уразаны сезгә фарыз итте, ә тәравих намазын сөннәт итте. Кем бу айда бер изгелек кылса, фарыз гамәлне үтәгән кебек булыр, ә кем фарыз гамәлне үтәсә, җитмеш фарызга тиң булыр. Рамазан – сабырлык ае, ә сабырлыкның нәтиҗәсе – җәннәт. Рамазан ае – уртаклашу ае. Ул айда мөселманның ризыгы киңәер, кем уразалы кешегә авыз ачтырса, тоткан кешенең әҗерен алыр, гөнаһысы гафу ителеп, үзен уттан саклар». Шуннан сәхабәләр сорадылар: «Йә Расүлуллаһ! Һәрберебез дә ураза тотучыга авыз ачтырырлык ризыктабаалмыйбыз».Пәйгамбәребез җавап итеп: «Ураза тотучыга бер йотым сөт яки су яки бер бөртек хөрмә булса да бирсә, Аллаһ аның әҗерен шиксез бирер. Ә кем инде ураза тотучыны тукландырып ашатса, аның бөтен гөнаһлары ярлыканыр, Аллаһ аны үзенең чишмәсеннән су эчертер вә шуннан соң ул беркайчан да сусамас һәм Аллаһы Тәгалә аңа ураза тотучы кешенең әҗерен бирер, ураза тотучының да, аңа карап әҗерен киметмәс».

Тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез әйтә: «Рамазан аеның беренче ун көне – рәхмәт, икенче ун көне– мәгъфирәт, өченче ун көне җәһәннәмнән котылу, кем бу айда үзенең малын сарыф итсә, Аллаһ аны уттан саклар».

Бу айда дүрт әйберне эшләргә тырышыгыз: икесеннән сез Раббыгызның ризалыгына ирешерсез, ә калган икесенә сез үзегез мохтаҗдыр. Раббыбызның ризалыгына ирештерә торган беренче ике гамәл – ул да булса (Ләә иләәһә илләллаһү) Аллаһыдан башка иләһ юк, дип даими шушы кәлимәне әйтү һәм истигъфар кылу, ә сез мохтаҗ булган гамәл ул да булса Аллаһтан даими җәннәтне эстәү һәм җәһәннәмнән сыгыну. Пәйгамбәребез бер көдси хәдисендә болай ди: «Аллаһы Тәгалә әйтә: «Адәм баласының кылган һәр гамәле үзе өчен, уразадан кала, чөнки ураза Минеке һәм әҗерен дә Үзем бирермен», – диде (Бохари, Мөслим). Никадәр гүзәл гыйбәдәт ул ураза, Аллаһ аны Минеке, дип безне шатландырды. Чөнки ураза риядан ерак булган бердәнбер гамәл. Ураза тотасыңмы, юкмы Аллаһыдан кала беркем дә белә алмый, гәрчә син үзеңне уразалы дисең дә. Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд әйтте: «Рамазанда минем өммәтемә биш әйбер бирелде, башка өммәтләргә ул бирелмәде:

ураза тотучының авызыннан чыккан ис, миск (ислемай) исенә караганда Аллаһка күпкә күркәмрәк;

авыз ачканчы фәрештәләр уразалы кешегә истигъфар укыр;

шайтаннар богауланыр;

һәр көнне ураза тоткан кеше өчен Аллаһ җәннәтне бизәп торыр;

рамазанның соңгы төнендә Аллаһы Тәгалә тулысынча аны гафу итәр».

Шунда сәхабәләр сорадылар: «Йә, Расүлуллаһ, ә ул Кадер кичәсеме?» Пәйгамбәребез җавап итеп: «Юк, һәр кеше берәр эшен тәмамласа, ахырда хакын алыр», – диде.

Инде йомгаклап пәйгамбәребезнең бер гүзәл сүзен язып үтик: «Ураза тотучы кешенең ике шатлыгы: берсе авыз ачкан вакытта, ә икенчесе, гөнаһыбыз гафу ителгән хәлдә Кыямәт көнендә Аллаһ белән очрашканда». Аллаһы Тәгалә күңелләребезгә иман, тәкъвалык бирсен.

Аллаһы Тәгалә уразаларыбызны кабул әйләп, гөнаһларыбызны гафу итсә иде. Амин!

**Тимергали хәзрәт Юлдашев,**
Татарстан мөселманнары
Диния нәзарәтенең
дәгъвәт бүлеге баш белгече

# БОЛГАР ИЛЕ



Борынгы Болгар дәүләтендә шул чорның башка бик күп мәмләкәтләрендәге кебек үк күп аллаларга табыну хөкем иткән. Хәтта кайбер халыкларда һәр көннең, атнаның, айның, ел фасылының, елның үз алласы булган. Күп гасырлар буе ата-баба йоласы булып килгән бу табынулар вакытында һәр аллага багышлап корбаннар бирелә торган булган.

Борынгы болгарлар ата-бабаларыннан калган гадәтләрне олылап яшәгәннәр. Ибне Фадлан раслаганча, элекке йолалар буенча еланны үтерергә ярамаган, аны зурлаганнар; яшен суккан өйне «каһәрләнгән» өй дип, анда тормыйча ташлап чыга торган булганнар. Каракларны һәм алдакчыларны бер дә яратмаганнар.

Болгарлар киемлек өчен нечкә бүз, постау җитештергәннәр һәм тула тукыганнар. Иген һәм сугыш коралларының, сугыш киемнәренең иң яхшыларын болгарлар ясаган. Бизәнү һәм киенү өчен кирәк булган көзге, беләзек, алка, сәдәп, каптырма, төймә кебек нәрсәләрне алтынкөмештән болгар осталары үзләре койганнар, акча сукканнар, сабын, шәм койганнар, төрле металларны эреткәннәр һәм тире эшкәрткәннәр, күн җитештергәннәр, гаҗәеп матур өс-баш һәм аяк киемнәре теккәннәр. Алар эшләгән әйберләр үзләренең матурлыгы һәм ыспайлыгы белән шул заман кешеләрен гаҗәпкә калдырган.

Болгарларда шул һөнәрләре өстенә игенчелек һәм урманчылык та бик яхшы үскән булган. Алар балык тоту белән дә шөгыльләнгәннәр. Үзләре җитештергән әйберләрнең артыгын чит мәмләкәтләргә сатканнар һәм болгармалларычитпатшалыкларның базарларында макталып, кыйммәт бәягә йөргән. Шуңа күрә дә болгарлар сәүдә эшендә бик оста булганнар. Аларның иң күп сату итә торган урыннары Болгар дәүләтенең башкаласы – Бөек Шәһәрдә һәм сәүдә кораблары килеп туктар өчен уңайлы урын – сәүдә гаване булган Болгар авылы янында булган. Ул вакытларда шәһәр дәрәҗәсендә булмыйча, Болгар авыл булып яшәсә дә, Идел буенда урнашканлыктан, көймә һәм корабларга малларын төяп чит патшалыкларга җибәрү өчен иң уңай урын буларак танылган. Башкаланың – Бөек шәһәрнең базарлары да, дөньяның төрле илләреннән мал төяп сәүдә итәргә дип килгән күпсанлы кәрваннарның бирегә килеп туктап, малларын бушатып, сату-алу эшенә керешү урынына әйләнгән Кәрвансарае да бик шәп булган һәм монда сәүдә кайнап торган.

Болгарга килгән сәүдәгәрләр үзләре белән бал, кеш, сусар, тиен, төлке, куян, кәҗә тиреләре, болгар күне һәм кәҗә тиресеннән ясалган югары сыйфатлы сәхтиян күне, балык, балык мае, балыктан ясалган җилем, мамонт теше, шәм, сабын, мөгез, чикләвек, төрле хайваннар, сугыш киеме, кылыч, ук, бүрек, кәләпүш, бортас туны дип аталган яхшы туннар, чигүле өс һәм аяк киемнәре, гәрәбә, бик күп төрле бизәнү әйберләре һәм башка шуның шикелле әйберләр алып китә торган булганнар.

Болгарлар бигрәк тә мөселман гарәпләр белән аралашып, алар белән дусларча алыш-биреш иткәннәр һәм мөселман гарәп патшалары белән Болгар патшалары һәрвакыт бер-берсенә хатлар язышып, илчеләр аркылы бүләкләр җибәрешеп, бик матур мөнәсәбәттә яшәгәннәр.

Ризаэддин Фәхреддин үзенең «Болгар вә Казан төрекләре» исемле хезмәтендә: «Греклар белән кайчакта сугыш һәм кайчакта солых хәлендә яшәгән иранлылар ял вакытларында да, тыныч вакытларда да болгарларда күрше урыннардан, күбесенчә, үзләренеңөсләреннәнөйрәнгәнлекләре һәм дә Европа белән булган сәүдәләре бөтенләй болгарлар өстеннән үткәнлектән, болгар төрекләре мәдәният юлына иртә кергәннәр, хәтта Иран белән Греция мәмләкәтләреннән соң өченче урында саналырга лаеклы булып кәсеп иткәннәр», – дип яза һәм, фикерен дәвам итеп: «Болгарлар иранлылар белән европалыларның сәүдәләренә арадашчы булыр өчен сәүдә эшләрен иртә өйрәнгәннәр, хәтта ике милләтнең сәүдәсенең үзәге булу өчен Болгар шәһәрен төзеп, сәүдә үзәге ясаганнар...», – ди. Аның фикеренчә, «болгарлар, читләрдән килгән нәрсәләрне алып озатып торуга канәгать итми, бәлки сәүдә белән ярышу юлына керәләр...».

Европа, Греция, Иран һәм Төркестан һәм Хорасан, Кытай һәм Һиндстан мәмләкәтләреннән Биләргә – Бөек Шәһәргә кәрваннар килеп сәүдә иткәннән соң, мал төяп, дөньяның төрле почмакларына китә торган булганнар.

Ризаэддин Фәхреддин фикеренчә, үзләре белән тыгыз сәүдә мөнәсәбәтендә, дус һәм тату яшәүче иранлылар һәм Урта Азия халыклары аркылы болгарлар Гарәбстан җирендә барлыкка килгән ислам дине турындагы хәбәрне бик иртә белгәннәр. Гарәпләр үзләре дә Болгар дәүләте аркылы башка илләр белән сәүдә мөнәсәбәтенә кергәнлектән, болгарлар белән аралашып, аларның тормыш-көнкүрешләренә йогынты ясамый калмаганнар.

Шиһабетдин Мәрҗани раславынча, болгарлар бик борынгы заманнарда ук инде ислам дине белән таныш булганнар һәм, гарәпләр белән эшлекле, тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләре урнашу нәтиҗәсендә Богар дәүләтендә ислам дине тарала башлаган. Үзенең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле китабында Ш.Мәрҗани: «Монда күп төрле ерак илләрдән галимнәр, сәүдәгәрләр, ә гарәпләрдән казыйлар, укытучылар һәм вәгазь сөйләүчеләр килә торган булган», – дип яза һәм Болгарның бик күп илләр белән тыгыз элемтәдә торганлыгына, анда гарәп миссионерларының килеп, дингә өндәүләренә ишарә ясый һәм болай дип дәвам итә: «Шәһре Болгар – җир йөзенең өч яки дүрт кисәгеннән берсе булган Европа өлешендәге Румия һәм Константинопольдән кала, иң элек мәдәнияте үскән Әндәлес мәмләкәтеннән соң, шул ук гасырда беренче булып ислам диненә кергән шәһәрдер».

Болгарда ислам дине дәүләт дине буларак рәсмиләштерелгәнче үк тарала башлавын күрсәтеп, Ш. Мәрҗани: «Бу мәмләкәт халкының исламга бик иртә керүе, аларны дингә өндәү өчен гарәп халкыннан табиблар кыяфәтендә дингә өндәүчеләр килгәнлегенә дәлил буларак беркадәр риваятьләр бар», – ди.

Болгар дәүләтенең төрле урынnarында ислам дине күп төрле юллар белән тарала башлаган. Ләкин бер генә җирдә дә дингә көчләү булмаган, ә халык динне үз теләге белән, ихтыярый кабул иткән. Бу хәлгә аңлатма биреп, мәшһүр галимебез Ризаэддин ибне Фәхреддин: «Борынгы бабаларыбызның үз ихтыярлары белән ислам динен кабул итүләрен фәкать аларның рухи халәтенең ислам дине кануннары белән тәңгәл килүеннән чыгып аңлатып була...», – дип яза.

Халыкның тормыш-көнкүреше, рухи дөньясы белән авазадаш булганга күрә, ислам дине Болгар дәүләтендә зур тизлек белән тарала. Мәчетләр салына, мәдрәсәләр ачыла, дөньяви һәм дини мәгърифәт нуры тарала башлый. Ислам дине белән бергә гарәп язуы кабул ителә, Шәрык фәне үтеп керә.

Болгарлар тыныч тормышта яшәп, бихисап күп төрле һөнәр-кәсепләре белән тормыш көткәннәр, үзләренең шәхси һәм ил байлыкларын арттырганнар. Нәкъ менә болгарларның тырыш хезмәтләре нәтиҗәсендә Болгар дәүләте үз чорында дөньяда алга киткән дәүләт булып танылган.

Болгар дәүләте кеременең күп өлешен дөньяның бик күп илләре белән уңышлы сәүдә итү, мал табу тәшкил иткән. Нигездә, Болгар дәүләте үзенең көндәлек тормышын һәм киләчәген дөнья илләре белән тыныч, үзара килешеп, ныклы сәүдә бәйләнешләре урнаштырып тәэмин иткән.

Гарәпләрнең Болгар дәүләтенә VII гасырның икенче яртысында ук килеп, дингә өндәүдән тыш башка эшләр белән шөгыльләнүләренә ишарәләп, Ш.Мәрҗани болай дип яза: «Гарәп халкы ислам дине барлыкка килгәч тә (!), бу мәмләкәткә аяк баса башлаган. Аларның бу өлкәдә көмеш ятмасы табып, билгеле булган зур бер елганы (Чулманның кушылдыгы) һәм мәгълүм бер өлкәне гарәп телендә Нократ (Көмеш) елгасы һәм ул өлкә халкын Нократ болгарлары дип атаган булулары шуны күрсәтә. Бу өлкә һәм елга хәзер дә шул исем белән йөртеләләр. Моның шулай булуы гарәп халкының күптән бу ил белән аралашуын күрсәтә. Шуңа күрә дә болгар халкы телендә бик күп гарәп сүзләре табыла...»

Мөселман гарәпләр үзләре яшәгән җирләрдә мәчетләр төзегәннәр, гыйбадәт кылганар һәм, кагыйдә буларак, һәр мәчет янында мәктәп-мәдрәсәләр ачканнар. Аларның бу гамәлләре җирле халык тарафыннан



хуплап кабул ителгән һәм болгарлар үзләре дә гарәпләр йогынтысында мәчетләр төзеп, мәктәп-мәдрәсәләр ачканнар. Шулай итеп, болгарларда ислам дине тарала башлаган һәм, шуннан чыгып, без Болгар дәүләтенә күп төрле юллар һәм сәбәпләр белән үтеп кергән ислам диненең беренче чаткылары кабыну чорын, урынын һәм сәбәбен ачыклауда тагын бер адым алга атлый алабыз...

Ислам дине кабул ителгәнче Болгар мәмләкәтендә рун язуыннан файдаланган булсалар, ислам дине кабул ителгәч, гарәп язмасы үтеп керә һәм әлеге язу бөтен Болгар дәүләтендә тарала. Бу язуны өстен катламнар гына түгел, ә бөтен халык, шул исәптән һөнәрчеләрнең дә белүенә дәлил булырлык язулы әйберләр табылуы мәгълүм. Инде X гасырның башында ук кайбер урыннарда ибтидаи мәдрәсәләр, ягъни башлангыч мәдрәсәләр барлыкка килә.

Ислам динен һәм шул чорда бөтен укымышлы Шәрык дөньясы куллана торган язуны кабул итү Болгар мәмләкәтенең матди, икътисадый, сәяси элементларен генә түгел, ә бик күп көнчыгыш дәүләтләре белән мәдәни багланышларын киңәйтүгә дә ныклы җирлек була һәм шуның нәтиҗәсендә мәдәният, мәгърифәт һәм төрле фәннәр үсеш ала. Төрле язма чыганакларда болгарларның үз араларыннан чыккан тарихчылар, философлар, табиблар һәм язучылар булганлыгы турында мәгълүматлар бирелә. Болгарлар арасында укый-яза белү шактый иң таралган була, чөнки мәчет булган һәр җирдә мәдрәсә дә эшләп килә һәм аларда мәгърифәткә, үз чоры өчен кирәк булган барлык фәннәргә һәм һөнәрләргә, суфичылык хикмәтләренә өйрәтү эше алып барыла. Шул чорларда безнең көннәргә кадәр яшәп килгән язма – ядкярләр дә иҗат ителә. Ш.Мәрҗани күрсәткәнчә, шундыйлардан «Нәһҗел-фәрадис» («Оҗмах бакчаларының ачык юлы»), «Башла Гали» («Кисекбаш»), «Йосыф китабы», «Нәсыйхәтес-салихин» («Файдалы киңәшләр»), «Бәдәвам» китаплары кебек төрки китаплар, «Нәүрүз» бәетләре, «Шәһри Болгар газилары» бәетләре бар иде. Ул шулай ук мондый китапларның бик күп табылуы, аларның башка мәмләкәтләрдә күрелгәне һәм ишетелгәне дә булмыйча, бары тик безнең якларда гына булуы турында яза.

Һичшиксез, болгарлар Шәрыктан килгән дини әдәбият белән генә түгел, ә үз чорының фәнни һәм әдәби әсәрләре белән дә яхшы таныш булганнар. Ә бу, үз чиратында, җирле болгарлы язучылар, шагыйрьләр һәм астрономия, медицина, фәлсәфә, тарих, хокук һәм башка фәннәр буенча галимнәр үсеп чыгуга җирлек булган. Шул чордан алып XX гасыр башына кадәр яшәп килгән халык медицинасы үзе генә дә безнең болгар бабаларыбызның һәм аларның изге эшен дәвам иттерүче соңгы буын вәкилләребезнең тапкырлыгына, акыл сәләтенә һәйкәл булырлык күренеш. Шәрык медицинасы, бигрәк тә Әбү Гали Синаның дәвалау ысуллары белән танышканнан соң, җирле табибларыбыз җирле шартларга яраклаштырып һәм җирле мөмкинлекләрдән чыгып, әллә никадәр дәвалау ысуллары уйлап чыгарганнар. Шуңа өстәп ислам дине белән пакьлек, сәламәт әхлак, шәхси гигиена кагыйдәләре дә керүне исәпкә алсак, бабаларыбызның ничек яшәвен күз алдына китерү кыен түгел. Биредә тирә-якта дан тоткан дарел-фөнүн, ягъни югары уку йорты булган һәм анда төрле фән тармаклары буенча белгечләр, галимнәр әзерләнгән.

Ислам дине кергәч, Болгар дәүләтендә инде шактый үсеш алган сәнгать яңа бер баскычка күтәрелә, замананың иң алдынгы Шәрык мәдәниятенә йөз белән борыла һәм аның шифалы йогынтысында үсүен дәвам иттерә...

Ибне Рустә үзенең 902-903 елларда язылган «Кыйммәтле хәзинәләр китабы»нда болгарлар арасында ислам диненең шактый авылларда таралуын хәбәр итә: «Аларның күпчелеге ислам динен тота, авылларда аларның мәчетләре һәм башлангыч мәктәпләре, мөәзиннәре һәм имамнары бар», – дип яза.

Нинди фәннәр укытырга кирәклеген, нинди белемнәр һәм һөнәрләр өйрәтергә икәнлеген ул чордагы тормыш үзе күрсәткән, үзе кушкан. Ул вакытларда теге яки бу һөнәр, кәсеп һәм яшәү өчен иң кирәкле булган фәннәр генә тирәнтен өйрәтелгәннәр һәм тормыш тәҗрибәсе белән беркетелеп барганнар...

Гамәли, матди мәдәнияткә, фәнгә, мәгърифәткә, сәнгатькә караган бәгъзе бер һөнәр-кәсепләреннән, гыйлем-белемнәреннән тыш, болгар бабаларыбыз тагын рухи мәдәниятебезгә мөнәсәбәтле күп кенә фәннәрне дә үзләштергәннәр һәм аларның нык үскән булуы да Болгар дәүләтенең халыкара дәрәҗәсен күтәргән. Фәлсәфә, мантыйк, тарих, әдәбият, сәнгать, икътисад, гыйльмел-бәләгать (матур сөйләм сәнгате), хәсне хат (матур язу сәнгате), хокук, халык авыз иҗаты, чит телләр өйрәнү һәм башка фәннәр буенча да төрле китаплар иҗат ителгәнлеген тарихи язма чыганаклар да раслый. Чыннан да бит, халыкара хокукларны, икътисадны камил белмичә, фәлсәфи фикерләмичә, мантыйклы итеп фикереңне аңлата алмыйча, чит телләрне белмичә торып, халыкара сәясәттә нинди уңышка ирешеп булсын да, тарихта, әдәбиятта, халык авыз иҗатында буыннан-буынга күчеп килерлек нинди халыкара зур дәрәҗәң булсын?! Әлеге фәннәрне нигезле итеп, төпле итеп өйрәнүләре өстенә болгар бабаларыбыз һәрберсе аерым вазыйфа башкарган, һәрберсе теге яки бу эштә генә махсус кулланылган бик күп төрле гарәпчә язу үрнәкләрен дә яхшы белгән һәм аларның серенә төшенүгә сабый чакта ук керешә торган булган.

Ә бит менә бу – югарыда атап киткән, тормыш итәр өчен генә кирәк булган дөньяви фәннәрдән тыш борынгы бабаларыбыз мәңгелек тормышлары – рухи тормышлары, диннәре-иманнары турында да онытмаганнар. Алай гына да түгел, динне нигез-асылын, дингә бәйле барлык фәннәрне өйрәнү иң беренче урында торган. Һәм шул сәбәпле дә инде Болгар дәүләте тирә-як мәмләкәтләр өчен дин белгечләре әзерләп чыгару үзәгенә әйләнә. Ә инде дин һәм иман әхлакның нигезен тәшкил итәләр. Динсез, имансыз кеше әхлаклы була алмый, әхлаксыз кеше динле, иманлы була алмый. Шуңа күрә дә Болгар дәүләтендә динсезлек, имансызлык, әхлаксызлык, алдау, талау, рәнҗетү, җәбер-золым, нахак сүз, ялган, хыянәт, җинаять кебек ямьсез, куркыныч сүзләр телдә дә йөрмәгән. Алар хәтта ерак төньякта яшәүче халыклар белән сәүдә итәргә баргач, малларын урман аланына куеп калдырып, җирле халыклар да болардан үрнәк алып, нәкъ болар кебек эшләп, бербәрсенә күренмичә, үзләренә кирәк кадәрле генә мал алып, шуңа тиешле бәядәге башка малны (җәнлек тиреләре һәм башка кирәк-ярак) куеп китә торган булганнар. Бу вакытта бернинди алдау, бернинди урлау-талау, бернинди хыянәт булмаган. Барысы да намуска, гаделлеккә, әхлакка корылган булган. Менә бу кечкенә генә бер мисал да бик күп нәрсәләр турында сөйли булса кирәк.

Кыскасы, болгар дәүләтендә рухи мәдәниятебезнең нигезен тәшкил иткән фән, мәгърифәт, мәдәният, сәнгать, әхлак, дин үз чоры өчен югары дәрәҗәдә үскәннәр, заманына, мәмләкәтенә лаеклы булганнар һәм аны башка дәүләтләргә караганда күпкә өстен чыгарганнар. Без мондый бай, шанлы һәм мәшһүр тарихыбыз белән хаклы горурланырга тиешбез!


**Әнвәр Хәйринең** «Әхмәд ибне Фадланның 921-922 елларда Болгар дәүләтенә килгәндә язган сәяхәтнамәсе» китабыннан




Коръән-каләм
• ЖК экран белән
• зур җәсҗфәле
• 15 төрдә
• күпләп һәм берәмләп сатыла
купонны күрсәтүчегә - Рамазан аенда 1 000 сум ташлама
+7 (843) 253-66-89, +7 (800) 700-73-45 Казан шәһәре, Астрономия урамы 3/16, 10 нчы офис, www.koran-pen.ru

Болгар түбәтәе


185 сумнан башлап
Тиңе булмаган кәләпүшләр ир-ат һәм хатын-кызлар өчен
– сәйлән һәм ташлар белән бизәлгән
– заказга исемле түбәтәйләр
– күпләп һәм ваклап алу мөмкинлеге
takbir-rt@mail.ru
www.tubeteika-kazan.ru
+7 (843) 2-926-919
+7 (987) 296-62-42
vk.com/club102487737
Казан, Тукай ур. 5

Хаж
120000 сумнан
+7(843) 524-92-10



ЦЕНТР ПАРТНЕРСКОГО БАНКИНГА
+7 (843) 200-07-27
www.cpbank.ru
Хезмәтебезне дини икътисади принципларга нигезләнеп, Татарстанның Диния нәзарәте Голәмалар шурасы фикере белән килештереп башкарабыз


## КАЗАН ӨЧЕН РАМАЗАН АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Авыз ачу/ Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 06.06.2016 | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 12:00 | 17:27 | 20:22 | 21:52 |
| 07.06.2016 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:28 | 20:24 | 21:54 |
| 08.06.2016 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:28 | 20:24 | 21:54 |
| 09.06.2016 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:29 | 20:25 | 21:55 |
| 10.06.2016 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:30 | 20:26 | 21:56 |
| 11.06.2016 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:30 | 20:27 | 21:57 |
| 12.06.2016 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:28 | 21:58 |
| 13.06.2016 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:29 | 21:59 |
| 14.06.2016 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:29 | 21:59 |
| 15.06.2016 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 16.06.2016 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 17.06.2016 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 18.06.2016 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 19.06.2016 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 20.06.2016 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 21.06.2016 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 22.06.2016 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 23.06.2016 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 24.06.2016 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 25.06.2016 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 26.06.2016 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 27.06.2016 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 28.06.2016 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 29.06.2016 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 30.06.2016 | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 01.07.2016 | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 02.07.2016 | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 03.07.2016 | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 12:00 | 17:33 | 20:29 | 21:59 |
| 04.07.2016 | 01:06 | 01:36 | 03:06 | 12:00 | 17:33 | 20:29 | 21:59 |
| 05.07.2016 | 01:07 | 01:37 | 03:07 | 12:00 | 17:33 | 20:28 | 21:58 |
| 06.07.2016 | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 12:00 | 17:33 | 20:27 | 21:57 |




## ӘХМӘДҺАДИ МАКСУДИ. «ГЫЙБАДӘТЕ ИСЛАМИЯ»

«Хозур» нәшрият йорты танылган татар галиме Әхмәдһади Максудиның «Гыйбадәте исламия» китабын нәшер итте.

Бу гыйльми әсәр гасырдан артык гыйбадәт кылуда ярдәм итүче классик дәреслек, татар халкының, мөселманнарның рухи мирасы булып санала. Китапта Хәнәфи мәзһәбе шәригате гадиләштерелгән вариантта тәкъдим ителә. Хезмәттә исламның биш баганасы турында сөйләнә. Аның мәгънәсе, нәрсә өчен кирәклеге һәм куллану рәвеше аңлатыла. Автор Әхмәдһади Максуди диндәге әһәмиятле һәм шул ук вакытта четерекле мәсьәләләрне гади һәм бар кешегә дә аңлаешлы тел белән бәян итә алган. Китап диндә беренче адымнарын ясаучыларга да, шул ук вакытта исламда күптәннән булучы кешеләр өчен дә файдалы һәм актуаль булып тора.

***

Әлеге китапны http://huzurshop.ru/ сайтыннан яки Казан шәһәре, Г. Тукай урамы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан кибеттән алырга мөмкин. Белешмәләр өчен телефон: +7 (843) 202-07-74.





ТАТАРЧА, РУСЧА, ГАРӘПЧӘ ДИНИ КИТАПЛАР

Мөселман сувенирлары һәм атрибутикасы.

Хәләл косметика.

ТЕЛЕФОН +7 (843) 202-07-74

издательский дом Хузур


Язылу индексы – 16046 Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

*Май саны, №5 (250)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К.И.**
Мөхәррир: **Кәбирова Н.Н.**
Дизайнер: **Даутов Р.А.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р.Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:** 420021, Казан шәһәре, Сафьян урамы, 8 нче йорт
**Электрон адресы:** naubahar67@list.ru
**Телефон:** +7 950 326 38 36

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хузур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Нияз САБИРОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмалар шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гәмәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).
**Нәшир:** «Хузур» нәшрият йорты (420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Сафьян урамы, 8 нче йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №3249
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга 16 нчы апрель көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.